• ӘҢГӘМӘ •

КОРЪӘН – РУХИ АЗЫК

*4 бит*

• СОРАУ-ҖАВАП •

ХӘЛӘЛ БУЛМАГАН РИЗЫКНЫ НИШЛӘТЕРГӘ?

*7 бит*

• ЗУР ГӨНАҺЛАР•

ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗГӘ ЯЛА ЯГУ

*10 бит*

• НӘСЫЙХӘТ •

ОЗЫН ГОМЕРНЕҢ СӘБӘБЕ

*12 бит*

*№ 12 (305)* *Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы* *Җөмәдәл-әүвәл 1442*

*Декабрь, 2020*

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ




*2021 ел Һиҗри буенча 1442 нче елның уртасына һәм ахырына, 1443 нче елның башына һәм уртасына туры килә. Һиҗри буенча календарь 12 айдан тора һәм мөхәррам аеннан башлана. Мөселман календаре буенча айларның башлануын һәм тәмамлануын билгеләгәндә, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы җирле географик үзенчәлекләргә һәм астрономик хисапларга таяна.*

***Дәвамы 8 нче биттә***

# Мөфти Апас мөхтәсибәте эшчәнлеген югары бәяләде



15 нче декабрьдә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин эшлекле сәфәр белән Апас мөхтәсибәтенә чыкты. Биредә ул район башлыгы Равил Хисаметдинов белән күреште, аның белән бергә төзелеп килә торган Мөселман яшьләре үзәге бинасын барып күрде һәм район мәдәният йортында мөселман өммәте белән очрашуда катнашты. Район хакимияте бинасында узган очрашуда сүз дини вәгазьләр, хезмәттәшлек юллары хакында барды.

Районның имам-мөхтәсибе Мирхәт хәзрәт Җамалиев ел дәвамында дин кардәшләребезнең матди ярдәме белән башкарылган эшләргә нәтиҗәләр ясады. Яңа төзелеп килә торган Мөселман яшьләр үзәге хакында сөйләде. Әлеге беркатлы бинам мөселманнарга белем алу һәм ял итү мөмкинлекләре тудырачак. Биредә намаз уку бүлмәсе, укытучылар бүлмәсе, тәһарәтханә, ашханә булачак. Мөселман яшьләре үзәгендә 7 яшьтән олырак балаларны хафизлыкка өйрәтәчәкләр. Малайлар һәм кызлардан торган ике төркем булдыру каралган. Бинаны киләсе җәйгә төзеп бетерү ниятләнә.

Алга таба мөфти хәзрәт, район башлыгы, кунаклар мөхтәсибәтнең еллык утырыш эшендә катнашу өчен район Мәдәният йортына юнәлде.

Беренче булып сәламләү сүзе һәм районның ирешкән уңышлары белән таныштырып Апас районы хакимияте башлыгы Равил Хисаметдинов чыгыш ясады. Аннары вәгазь, дини нәсыйхәт сүзләре белән мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин сүз алды. Ул гонаһны ничек җиңү мөмкинлеге хакында танылган галим, рухи остаз Ибраһим Әдһәм китергән нәсыйхәтләрне искә төшереп узды.

Алга таба 2020 елга мөхтәсибәт эшчәнлегенә нәтиҗәләр белән районнның имам-мөхтәсибе Мирхәт хәзрәт Җамалиев таныштырды. Ул балалар, авыр хәлле гаиләләр белән эш тәҗрибәсе, балалар бакчасы һәм мәктәпләр белән хезмәттәшлек итү юллары турында сөйләде. Мөфти мөхтәсибәтнең 2020 елда башкарган эшчәнлеген һәм аның нәтиҗәләрен югары бәяләде, имамнарга эшләгән эшләре өчен тирән рәхмәтен белдерде. Очрашу барышында күп еллар имам-хатыйб булып эшләүче Бигеш авылы имам-хатыйбы Фәрит Бикмөхәммәт улы Ярмиевка нәзарәтнең медале һәм башка хезмәт алдынгыларына мөфти хәзрәтнең һәм мөхтәсибәтнең рәхмәт хатлары тапшырылды. Очрашуның икенче өлешендә Камил хәзрәт сорауларга җавап бирде, аерым алганда, алар зәкят һәм садака бирү, җомга намазын уку, covid-19 авыруыннан вафат булучыларны җирләү, зиратларны тәртиптә тоту мәсьәләләренә кагылышлы булды. Моннан тыш, Камил хәзрәт «Хозур ТВ» мөселман каналының географиясе киңәю, киләсе елдан татар һәм рус телләрендә мөстәкыйль каналлар барлыкка килү, нәшрияттa басмага әзерләнә торган яңа китаплар белән таныштырып үтте. Катнашучылар «Хозур ТВ» каналы тапшыруларын югары бәяләделәр һәм тапшырулар программасын район газетасында бастырып чыгару мөмкинлеген карауны сорадылар. Моннан тыш, имамнар нәзарәт тарафыннан әзерләнгән Гыйбадәт кылулар турындагы нигезләмә әзерләнеп кабул ителү өчен мөфтигә рәхмәт сүзләрен җиткерделәр, мөфти хәзрәтне киләчәктә вәгазь кичәсенә чакырып калдылар.

■ **dumrt.ru сайтыннан**

# Балтач мөхтәсибәтендә җыелыш узды

17 нче декабрьдә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Балтач мөхтәсибәтенә эшлекле сәфәр кылды. Биредә район мөхтәсибәтенең 2020 елда башкарылган эшчәнлегенә нәтиҗәләр ясалды.

Татарстан мөселманнары башлыгын республикабызның баш казые һәм Балтач районы имам-мөхтәсибе Җәлил хәзрәт Фазлыев, район имамнары белән берәттән, күрше районнардан – Кукмара мөхтәсибе Рәдиф хәзрәт Тимергалиев, Теләче мөхтәсибе, төбәк казые Исмәгыйль хәзрәт Фәләхиев каршы алды.

Беренче эш итеп Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, тирә-як районнарның имам-мөхтәсибләре һәм башка кунаклар Балтач районы Норма авылында булды, алар биредәге мәчет каршындагы курслар эшчәнлеге белән таныште. Норма авылында дини дәресләрне үткәрү өчен махсус бина төзелеше 2018 елда башланды. Аның төзелеше эшмәкәрләр һәм авыл халкы ярдәме белән алып барылды. Бина быелның 18 октябрендә ачылды һәм белем алу өчен барлык мөмкинлекләр булдырылды. Биредә бик теләп яше-карты дини белемнәрен арттыра ала, барлыгы 6 укытучы белем бирә. Җәлил хәзрәт яшь буынга рухи-әхлакый тәрбия һәм ислам кыйммәтләрен җиткерүдә мәчет каршындагы курсларның әһәмиятен билгеләп, бинаны төзүчеләргә, биредә белем бирүче мөгаллимнәргә рәхмәт сүзләрен җиткерде. Аннары мөфти хәзрәт катнашында мәктәпкәчә яшьтәге балаларның чыгышлары тыңланды, алар Коръән аятьләрен укып күрсәтте, дини шигырьләр, мөнәҗәтләр сөйләде. Камил хәзрәт яшь буын вәкилләренең чыгышларын югары бәяләп, балаларга бүләкләр тапшырды.

Алга таба кунаклар Балтач мөхтәсибәтенең еллык йомгаклау җыелышында катнашу өчен Балтач Үзәк мәчетенә юнәлде. Җыелышта Балтач районы Башкарма комитеты җитәкчесе Айдар Хәйретдинов, республикабызның Теләче, Кукмара, Саба, Әтнә мөхтәсибләре, Балтач мөхтәсибәтенең уку-укыту, яшьләр эшләре, дәгъват өчен җаваплы вәкилләре, Балтач районының 44 мәчетеннән килгән имамнар, мөгаллимнәр, абыстайлар катнашты. Коръән уку белән башланып киткән җыелышта Җәлил хәзрәт мөфтине һәм башка кунакларны ел дәвамында мөхтәсибәттә башкарылган эшләр белән таныштырды. Имам-мөхтәсиб дөньякүләм пандемия шартларында да районда балалар өчен рухи тәрбия бирү эшчәнлеге тукталмавына игътибар юнәлтте, балалар өчен төрле чараларның дистанцион форматта үткәрелүен дә ассызыклап узды. Җәлил хәзрәт нәзарәт җитәкчелегенә коронавирус пандемиясе көчәйгән вакытта мәчетләргә җибәрелгән матди ярдәмнәр өчен зур рәхмәтен җиткерде. Әлеге финанс мөмкинлек тиешле чаралар күреп, кичекмәстән мәхәллә халкы белән эшчәнлекне тукталмаска этәргеч бирүне, яшь буынга әхлакый тәрбия бирү эшен алып бару өчен зур ярдәм итүен билгеләп үтте.

Алга таба барлык кунакларны һәм имамнарны сәламләү сүзе белән мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин чыгыш ясады. Ул мөхтәсибәттә башкарылган күпкырлы эшчәнлекне югары бәяләде, киләсе елга максат-бурычлар куйды һәм вәгазь, нәсыйхәт сүзләрен җиткерде:

– Иң динсез кеше дә иң ким дигәндә мәчетләребезгә өч тапкыр килә – тугач, өйләнгәндә һәм үлгәндә. Тәнкыйтьләсәләр дә, алар барыбер имамнарга мохтаҗ. Шуңа күрә сабыр булыйк. Аллаһы Тәгалә Үзе риза булырлык гамәлләр кылырга насыйп итсә иде. Игелекләребез өчен Раббыбыз савапларын арттырсын, ике дөньяда да Үзенең чиксез мәрхәмәтен бирсен. Нәрсә генә эшләсәк тә, барыбер тәнкыйть сүзе әйтелер. Андый чакта нишләргә? Безгә эшләргә кирәк, Аллаһы ризалыгы өчен эшне дәвам итәргә кирәк. «Син барлык кешеләрне дә разый итә алмаячаксың. Шул сәбәпле, Раббың белән элемтәне нытыт, Раббың белән араң яхшы булганнан соң, кешеләргә игътибар итмә», – дигән имам Шәфигый. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткәнчә, кем дә булса кешеләргә рәхмәтле була алмаса, ул Аллаһыга да рәхмәтле була алмый.

Шул уңайдан мөфти хәзрәт хезмәт алдынгыларына рәхмәт хатлары тапшырды, ә Балтач Үзәк мәчетенең имам-хатыйбы Рамил Бикбаевны нәзарәтнең медале белән бүләкләде.

■ **dumrt.ru сайтыннан**

# Татарстанның иң борынгы таш мәчете ачылды



11 нче декабрьдә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында төзекләндерүдән соң Әтнә районы Түбән Бәрәскә авылында урнашкан, 1769 елда төзелгән борынгы таш мәчет тантаналы рәвештә ачылды. Әлеге чарада Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР Президенты Аппараты Җитәкчесе Әсгать Сәфәров, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов, Әтнә муниципаль районы башлыгы Габделәхәт Хәкимов, Әтнә районы Ленин исемендәге совхоз җитәкчесе Илгиз Хәйруллин һ.б. катнашты.

Чара Коръән аятьләре уку белән башланып китте. Аннары Татарстан Президенты сүз алды. Ул бүгенге шатлыклы җыелышны бөтен татар халкы өчен зур тантана дип атады. Бәрәскә авылы халкына котлауларын, әмәчетне төзекләндерүдә катнашкан һәркемгә үзенең рәхмәтен җиткерде. «Киләчәктә дә безнең республикабызда мәчетләр гөрләп торсын. Мәчеткә яшьләрне тартырга кирәк, яшьләр дә йөрсен», – дигән теләген белдереп, Рөстәм Нургали улы мәчетнең татар халкы тормышындагы әһәмиятен ассызыклады, аны гореф-гадәтләрне саклаучы һәм укыту урыны дип тә атады.

Алга таба Әтнә районы Түбән Бәрәскә авылының 1769 елгы мәчетне реставрацияләү хәйрия фондын гамәлгә куючы Илгиз Хәйруллинга сүз бирелде:

– Әлеге мәчетне төзекләндерү безнең авыл өстендә зур бурыч булып тора иде. Бүген, Аллаһыга шөкер, без бу бәхетле көнгә ирештек. Монда җыелган һәр кешенең дә бу мәчетнең шушы матур халәткә килүендә үз өлеше бар. Һәркайсыгызга да Аллаһы Тәгаләнең олуг рәхмәтләре яусын! Мәчетнең иң төп бизәге – намаз укучылар. Безгә шушы мәчетне тутырып намазларга йөрергә язсын!

Мәдәни мирас бинасы булган мәчет рәсми рәвештә ачылганнан соң, кайткан кунаклар һәм җыелган халык беренче җомга намазына узды. Күп еллар укылмый торганнан соң тарихи мәчеттә беренче вәгазьне Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин сөйләде. Җомга вәгазе игелекле гамәлләр кылу, Аллаһы юлында ихласлы булу, тырышлык күрсәтү хакында барды. «Мәчетне төзекләндерү өчен күп кеше тырышлык куйган, – дип искәртте Камил хәзрәт. – Аларның бу савaплы эшкә күпме көч китүкәнен алар үзләре һәм Раббыбыз гына белә. Ул гына безнең игелекләрне Күрүче һәм әҗер-савапларны Бирүче. Шуңа күрә хәерле гамәлләрне кешеләрдән рәхмәт ишетү өчен түгел, ә Аллаһы ризалыгы өчен башкарырга кирәк». Фикерен йомгаклап мөфти хәзрәт имам Шәфигыйның сүзләрен китерде: «Син барча кешеләрне дә разый итә алмаячаксың. Шул сәбәпле, Раббың белән элемтәңне ныгыт. Раббың белән араң яхшы булганнан соң, кешеләргә игътибар итмә».

Камил хәзрәт Аллаһы Тәгалә Үзе риза булырлык гамәлләр кылырга насыйп кылсын, игелекләребез өчен Раббыбыз савапларын арттырсын, ике дөньяда да Үзенең чиксез мәрхәмәтен бирсен дип теләкләрен җиткерде. Соңыннан җәмәгать җомга намазын укыды.

1769 елда төзелгән Түбән Бәрәскә мәчете Төбәк күләмендә әһәмияткә ия булган мәдәни мирас һәйкәле булып тора. Ул – Казан ханлыгы чорыннан соң татар җирендә төзелгән беренче таш мәчет.

XVIII гасыр архитектура һәйкәле булып саналган таш мәчет Ибраһим бине Йосыф морза акчасына салынган. "Петербург бароккасы" стилендә корылган. Шунысы да кызыклы, Казандагы моңа охшаш "Мәрҗани" мәчете 1770 елда, Бәрәскә авылындагы мәчеткә караганда бер ел соңрак ачыла.

Бәрәскә мәчете төзелү турында Шиһабетдин Мәрҗани «Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр» исемле танылган тарихи хезмәтендә язып калдыра: «Авыл уртасындагы таш мәчетне шул авыл кешесе Ибраһим бине Йосыф бине Әснай бине Исәнкол бине Борнагыл 1183 (1769) ел азагында бик нык итеп, баскычларын чуеннан ясатып салдырган».

■ **dumrt.ru сайтыннан**

# Казанда Ислам фәннәре, гарәп теле буенча Бөтенроссия олимпиадасы үтте

18 нче декабрьдә Рәсәй ислам институтында Ислам фәннәре һәм гарәп теле буенча ислам уку йортлары студентлары арасында XIII Бөтенрәсәй олимпиадасы җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы узды. Олимпиадада Татарстан, Дагыстан, Чечня, Кабарда-Балкар, Мордовия, Карачай-Чиркәс, Түбән Новгород, Уфа һәм башка шәһәрләрдән егерме дүрт мөселман уку йортыннан студентлар катнашты. Алар язмача биремнәр эшләде, дөрес һәм матур итеп Коръән укыды һәм телдән сөйләм осталыгын күрсәтеп көч сынашты. Җиңүгә иң лаеклы студентлар РИИ ректоры Рафикъ хәзрәт Мөхәммәтшин кулыннан планшет, айфон, ноутбук, «акыллы сәгать» кебек бүләкләр алды.

Белемнәрне сынау ярышында иң яхшы нәтиҗә күрсәтүчеләрне бүләкләү чарасы Коръән аятьләре уку белән башланып китте. Аннары сәламләү сүзләре белән Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин чыгыш ясады. Ул барлык гамәлләрне Аллаһы ризалыгы өчен эшләргә кирәклекне искәртте, аннары катнашучыларга диндә хикмәтле булуның әһәмиятен ассызыклап, нәсыйхәтләрен җиткерде. «Исламны хикмәт белән аңлатырга кирәк. Аллаһы хикмәт биргән кешегә бик күп хәер биргән. Аллаһы Тәгалә белем генә биреп калмыйча, алган белемнәр белән куллану, аны тарату өчен дә мөмкинлекләр бирсә иде. Гамәлсез гыйлем җимеш бирми торган агачны хәтерләтә. Спорт уеннарында катнашканда көч сарыф ителәә, ә олимпиадага әзерләнеп, укып алган белемнәр киләчәк буыннар өчен хезмәт итәчәк. Аллаһы барыбыздан да разый булсын», – дип теләкләрен җиткерде ул.

Рәсми чыгыштан соң мөфти хәзрәт үз исеменнән махсус бүләк тапшырды. Әлеге кызыксындыру призына «Гарәп теле» номинациясе буенча IV урын яулаган шәкерт – Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсенең III курс студенты Рамазан Сабиров лаек булды. Ул Арча районы Яңа Кенәр авылыннан, мәдрәсәдә барлык фәннәрне яхшы үзләштерүе һәм җәмәгать эшләрендә актив катнашуы белән аерылып тора. Мөфти кулыннан шәкертнең бүләген аның укытучысы Равил хәзрәт Бикбаев кабул итеп алды.

Алга таба шулай ук Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының телләрне үстерү һәм иҗтимагый оешмалар белән үзара бәйләнешләр бүлеге башлыгы Илнур Шакиров, әлеге мөһим чараның 13 ел рәттән башкалабызда үтүен билгеләп, кызыксындыру бүләкләрен тапшырып узды.

Татарстан мөфтиенең мәгариф буенча урынбасары, РИИ ректоры Рафикъ Мөхәммәтшин «Гарәп теле», «Дин нигезләре», «Ислам хокукы», «Мәдрәсәләрдә ислам хокукы» номинацияләре буенча I, II, III урыннарны яулаучыларны бүләкләде.

■ **dumrt.ru сайтыннан**

# «Коръән – рухи азык»

**Раббыбызның иң соңгы китабы – ул Коръән. Мөселманнар Аллаһы Тәгаләнең шушы ахыргы Изге Китабын Кыямәт көненә кадәр, ягъни бу дөнья беткәнче, кешелеккә яшәү өчен өйрәтмә һәм Ахирәткә әзерләнү өчен кулланма буларак кабул итә.**

**ТҖ МДНнең Шәригать сораулары бүлегенең баш белгече, Коръәнне өйрәнү үзәгенең җитәкчесе, Коръән-хафиз Илнур хәзрәт Хәйруллин белән Аллаһының Изге Китабы булган Коръән, аны ятлауның фазыйләтләре хакында әңгәмә кордык.**

**– Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ, Илнур хәзрәт.**

– Вә галәйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү!

**– Әңгәмәбезне башлап, сездән иң элек Коръән хакында сорыйсы килә. Әлеге Изге Китап турында күбрәк сөйләгез әле.**

– Коръән – ул Аллаһы Тәгаләнең сүзе, ул Коръәнне Аллаһы Тәгалә Җәбраил галәйһиссәлам аша безнең Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә 23 ел дәверендә аятьләп-аятьләп яки сүрә, кыска сүрәләр итеп иңдерде. Кайбер аятьләр сорау сәбәпле иңдерелде, мәсәлән, сәхабәләр кайбер сораулар бирәләр иде. Кайберләренең ни өчен иңдерелгәннәрен Аллаһы Тәгалә Үзе генә белә.

Аллаһы Тәгалә Коръәнне ни өчен иңдерде? Аллаһы Тәгалә безне бу дөньяга яратты, шулай бит? Һәм безне ташлап калдырмады. Яратучы Үзе яраткан мәхлукъны белә: аңа нәрсә кирәк, нәрсә кирәкмәс, ничек яшәячәген – менә боларны бары тик Аллаһы Тәгалә генә белә. Шуның өчен безгә менә бу Коръәнне иңдерде, без аларны (сүрә-аятьләрне) укып, фикерләп, шуның белән яшәсен өчен.

Асылда бөтен кеше бәхетле булырга тели, шулай бит? Бәхетне Аллаһы Тәгалә Ислам динендә яшергән. Әгәр кеше Коръән кушканча яшәсә, бәхетле була, бәхетен таба. Кем кире кага, бу бәхетсез кеше була.

**– Болай булгач, мөселман кеше Коръәнне өйрәнергә тиешме? Ничек итеп? Коръәнне укый белмәсә, нишләргә кирәк?**

– Коръәнне укый белмәсә, күпмедер микъдар өйрәнү аңа фарыз булып тора, чөнки аятьтә Аллаһы Тәгалә Коръәнне тәртил белән укырга әмер итә. Тәртил дигән нәрсә – (хәрефләрнең) дөрес мәхраҗларын, сыйфатларын чыгарып, тәҗвид кагыйдәләренә буйсынып укырга әмер итә. Без инде аны намазда уку сәбәпле, безгә ул фарыз, чөнки намазда дөрес укымасак, безнең намаз дөрес буламы яки дөрес булмыймы, без аны белмибез. Күпмедер микъдар дигәндә, намазга җитәрлек «Фатиха» һәм берничә сүрәне әйтәбез. Шуның өчен без ким дигәндә, аларны дөрес итеп укырга өйрәнергә тиешбез. Бу инде фарыз булып тора. Ә инде Коръәнне ачып, аңа карап уку – бу сөннәт гамәл, ягъни кеше Коръән укымаса, гөнаһлы булмый, ләкин күп әҗер-саваптан, бәрәкәттән мәхрүм кала.

**– Димәк, кеше савап алу максатыннан көннең күпмедер өлешен Коръәнгә бүләк итәргә тиеш?**

– Әйе, әгәр кеше савап алырга теләсә, Коръәнне күпмедер микъдар укырга тиеш. Сәхабәләрнең: «Кешегә буш вакытында кулына Коръән алып берничә аять укырга нәрсә комачаулый?» – дип әйткән сүзләре дә бар. Коръәннең фазыйләтен сәхабәләр безгә караганда яхшырак аңлаганнар. Безгә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә: «Коръән укыгыз, Кыямәт көнендә ул сезгә шәфәгатьче булачак», – дип әйткән һәм Коръән укырга әмер иткән.

**– Илнур хәзрәт, әгәр кеше гарәп хәрефләрен генә белсә, ләкин тәҗвид фәнен белмәсә, ул кешегә Коръәнне ачып уку нинди фазыйләт булып тора? Әллә ул иң элек тәҗвидне өйрәнергә тиешме?**

– Әйе, әйткәнемчә, әгәр кеше Коръән укырга өйрәнергә теләсә, иң элек ул тәҗвидне өйрәнергә тиеш, чөнки дөрес итеп уку – фарыз. Шунысын да искәртеп үтәргә кирәк, гарәп хәрефләрендә йомшак хәрефне калын әйтсәң яки калынны йомшак итеп әйтсәң дә, яки кайбер җирләрдә сузып җибәрсәң, йә киресенчә, сузмасаң, сүзнең мәгънәсе үзгәрә. Шуның өчен дә без Аллаһының сүзләрен укыганда сүзнең мәгънәсен үзгәртеп укысак, моның өчен савап булмый, киресенчә, кешегә гөнаһ язылырга мөмкин.

**– Яңа гына Исламга килгән, ләкин әле дини гыйлеме булмаган олы яшьтәге кеше остаз белән генә сүрәне ятлый аламы? Мәсәлән, шул ук «Фатиха» һәм берничә кыска сүрәне тәҗвид фәнен өйрәнмичә генә ятларга мөмкинме?**

– Әйе, алай да мөмкин, чөнки тәҗвид фәнен теория, ягъни фән буларак белү – фарыз кифая булып тора, хөкеме шундый. Фарыз кифая – бер мәхәлләдә берничә кеше белсә, башкаларның өсләреннән төшә торган гамәл, ягъни фарыз булмый. Әйтик, мәхәллә тирәсендә яшәүчеләрдән берәү дә белмәсә, барысы да гөнаһлы була. Арасыннан берсе булса да өйрәнергә тиеш була. Әгәр араларыннан берсе яки



берничәсе өйрәнсә, башкаларның өстеннән төшә. Шулай да имам яки мөгаллим белән берничә сүрәне булса да дөрес итеп өйрәнү хуплана.

**– Әгәр кешенең Коръәнне тулысынча ятларга теләге булса, моның өчен аңа күпме вакыт таләп ителә?**

– Бу мәсьәлә күбрәк кешенең зиһене белән бәйле. Әгәр кеше тырышып, көненә Коръәннән берәр бит ятлап барса, уртача ике ел кирәк. Ләкин әле ул кешенең яшенә дә карый, ягъни олы яшьтәге кешеме, яшь кешеме. Анысы да мөһим, чөнки яшь кеше тизрәк үзләштерә, ә олы кешегә өйрәнер өчен күбрәк вакыт таләп ителә.

**– «Коръән укыйсыңмы яки ятлыйсыңмы?» – дигән сорауга кайберәүләр: «Эштән арып кайтам, моңа вакытым җитми», – дип җавап кайтаралар. Коръәнгә якынрак булу өчен сез бу кешеләргә нинди нәсыйхәт бирер идегез?**

– Минем бер шәкертем бар иде. Тәзелеш өлкәсендә эшләде. Ул иң элек кыска сүрәләрне ятлаудан башлады. Юлда машинасында барганда һәм кайтканда да кабатлый иде, эштән кайткач та кабатлый иде. Шулай 2-3 ел эчендә Коръән ятлауны тәмамлады. Ул хәзер дә әле дәвам итә, хәдисләр ятлый. Бу инде кешенең кызыксынуыннан килә. Эштән арып кайтканны көтәргә кирәк түгел, киресенчә, эштә 5 кенә минут буш вакытың бар икән, шул чагында син Коръәнне ачып укый яки өйрәнгәненңне кабатлый аласың. Транспортта йөргәндә күргәнегез бар бит, кулына китап тотып укып баручылар бар. Безгә дә кулыбызга Коръән алып, аны укып барырга беркем дә комачауламый. Без бит чәй эчәргә дә 5-10 минут кына вакыт табабыз. Теләк булганда Коръән укырга да вакыт табарга мөмкин. Әйткәнемчә, ул кешенең кызыксынуына бәйле. Кешенең ихласлыгы зәгыйфь икән, ул аны төрле сәбәп табып кичектерәчәк. Әмма дә ләкин кеше арыса да, Коръән уку кешегә ял бирә. Коръән – ул рухи азык. Сәхабәләр бит бер-берсен нәфел намазларын укырга, ял итеп алырга чакырганнар. Шуның кебек, Коръән укып кеше арымый, киресенчә, ял гына итә.

**– Хәзрәт, Коръәнне балаларга ничә яшьтән өйрәтү фазыйләтлерәк? Балаларга авыр да булмасын һәм шул ук вакытта соңга да калмас өчен.**

– Балаларны иртәрәк хәреф танырга өйрәтә башласак, шулчаклы әйбәтрәк. Гарәпләрдә шундый әйтем бар: «Карт чакта ятланган, суга таяк белән сызган кебек булса, ә яшь чакта ятланган ташка уеп язуга тиң». Ягъни ташка уеп язган нәрсә гомерлек, ул үзгәрми. Шуның кебек, яшь чакта ятланганны ул онытмый, искә төшерүе дә җиңел була. Олыгайган яшьтә ятласак, гел кабатлап торасы була.

**– Димәк, 40 яшьләрдә Коръәнне ятлау, ул инде соң? Кеше бит әле Ислам динен шул яшендә генә кабул итәргә мөмкин, ләкин Коръән ятларга зур теләге булуы бар.**


– Сәхабәләргә карасак, алар арасында күбесе Коръәнне 40 яшьләр тирәсендә ятлаганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә дә вәхи 40 яшендә генә иңә башлаган, ягъни ул да Коръәнне шул яшендә генә ятлады. Ләкин шуны да искәртеп үтәргә кирәк, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның сәхабәләре дә гарәп телен камил, югары дәрәҗәдә белүчеләр. Сүз дә юк, гарәп телен белү, бигрәк тә камил дәрәҗәдә белү Коръән ятлауны күпкә җиңеләйтә. Әмма дә ләкин 40 яшендә ихлас күңеле белән ятласа, кешенең ихласлыгы һәм тырышлыгы булса, авырлыкларга сабыр итсә, иншәАллаһ, бу кеше булдыра ала.

*Дәвамы киләсе санда*

■ **Әңгәмәне Ленар Хамматов оештырды**

# Юныс галәйһиссәлам кыйссасы

***Дәвамы. Башы алдагы санда***



Юныс галәйһиссәлам үз хатасын аңлап алып, дөм караңгыда – балык карынында утырып Аллаһыны зикер итә:

**«[Расүлем!] Балык иясен дә [искә ал]! Менә ул [Юныс [галәйһиссәлам] ярсыган хәлдә [кавемен ташлап] киткән иде дә, Без, аңа каршы хөкем бирмәячәкбез дип, санаган иде. [Утырган бер көймәдә, шобага нәтиҗәсендә, диңгезгә ыргытылуыннан соң аны йоткан балык эчендәге] Караңгылыклар эчендә: «Синнән башка һичбер илаһ юк! Син пакь! Һичшиксез, мин залимнәрдән булдым!» – дип дәште».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:87

Коръәндә шулай ук Юныс галәйһиссәламнең әлеге догасы кабул булуы һәм Аллаһының аны гафу итүе әйтелә:

**«Без аңа җавап бирдек һәм аны [йоткан балыкка: «Бераздан аны диңгез ярына илтеп чыгар!» – дип әмер итеп] хәсрәтеннән коткардык. Мөэминнәрне дә шулай коткарырбыз».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:88

Шушы тәсбих, Юныс галәйһиссәламнең алдагы тормышында әйтелгән бик күп башка зикерләре кебек үк, күкләргә аша. Үз гомерендә ул Аллаһы Тәгаләне бихисап зикер кылганга күрә, фәрештәләр хәтта аның тавышын да белгәннәр. Бу юлысы да алар Юныс галәйһиссәламне тавышыннан танып ала һәм болай диләр: «Ий Раббыбыз! Бу Юныс галәйһиссәламнең тавышы түгелме? Син һәрвакыт аңа рәхмәтле булдың, бу юлы аны бәладән коткармассыңмы?»

Нинди гаҗәп! Җирдә яшәүчеләрнең берсе дә Юныс галәйһиссәламгә ярдәм итә алмый, чөнки аның кайда булуын да белмиләр, ләкин аңа ярдәмгә күк ияләре үзләре үк ашыга! Һәм Аллаһы балыкка Юныс галәйһиссәламне ярга чыгарырга әмер бирә. Шул рәвешле, Юныс галәйһиссәлам бәладән котыла.

Бу күренештә Яратучыбызның бөек хикмәте ята: пәйгамбәрне үзенең имин көннәрендә күп тапкырлар әйткән зикерләре коткара. Даими рәвештә Аллаһыга рәхмәтеңне, яратуыңны һәм Аңа бар яктан бирелгәнлегеңне белдереп ихластан зикер әйтү кешене киләчәктә күпләгән авырлыклардан һәм бәлаләрдән коткара ала.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

**«Әгәр дә ул [тыныч чорда Аллаһыны күп зикер итеп] тәсбих итүчеләрдән булмаса. Алар терелтеләчәк көнгә кадәр аның карынында көтәчәк [һәм бөтен кеше кабереннән чыккан вакытта, ул балыкның карынында терелтеләчәк] иде».**

«Саффәт / Сафта торучылар», 37:143-144

Әлеге аять ачыктан-ачык рәвештә бәхетлеимин вакытта Аллаһыны зикер кылучыга авыр мәлдә, һичшиксез, ярдәм булачагын күрсәтә.

Төрле риваятьләр буенча, Юныс галәйһиссәлам балык карынында өч, җиде яки кырык көн булган, дип әйтелә. Ул балык карыныннан мөхәррам аеның унынчы көнендә (Гашура көнендә) чыккан. Балык Юныс галәйһиссәламне яр буена чыгаргач, ул Аллаһы Тәгаләгә үзенең котылуы өчен чиксез рәхмәтләрен әйтергә тотына.

Кәлам Шәрифтә Юныс галәйһиссәламнең котылуы турында түбәндәгеләр әйтелә:

**«Ул авыру хәлдә булганда, Без аны буш бер җиргә ташладык. Һәм [ябырылган черкиләрдән, кояш кызулыгыннан саклау өчен] аның өстенә [киң яфраклы] кабак агачы үстердек».**

«Саффәт / Сафта торучылар», 37:145-146

Юныс галәйһиссәлам балык карыныннан чыгып котылганда бик ябыккан, бетәшкән, хәлсез һәм ярдәмгә мохтаҗ булган. Аллаһы Тәгалә аның янәшәсенә зур һәм киң яфраклы үсемлек үстерә, әнә шулай итеп аны кояш эссесеннән һәм чебен-черкиләрдән саклый.

Бер риваятьтә әлеге үсемлек сөт бүлеп чыгарган, аның белән Юныс галәйһиссәлам тукланган дип әйтелә. Башка бер риваятьтә Аллаһы Тәгалә Юныс галәйһиссәламгә тау кәҗәсен буйсындыруы, аның иртән һәм кич килеп, пәйгамбәргә үзенең сөтен биргәнлеге хакында искә алына. Хәлсезлектән котылгач һәм көч җыйгач, Юныс галәйһиссәлам гыйбадәт кылырга керешә. Ул Аллаһы Тәгаләгә түбәндәге дога белән мөрәҗәгать итә:

**«Ий Раббым! Барлык әмерләр һәм карарлар Синнән генә. Әмма мин бик тә Ниневиягә кайтырга һәм үземнең иман китергән халкымны күрергә өметләнәм. Моның белән берррәттән, мин Синең һәрбер карарларың белән риза булачакмын».**

Һәм Аллаһы аңа үз халкын хакыйкатькә чакыру бурычын янә йөкли.

Габдулла бине Габбас радыяллаһу ганһедән килгән риваятьтә хәбәр ителгәнчә, Юныс галәйһиссәлам йөз егерме мең кешене тәшкил иткән халыкка пәйгамбәр сыйфатында җибәрелгән. Әлеге халыкның саны турында Коръәндә болай дип әйтелә:

**«Без аны [сәламәтләндереп, рөхсәтсез ташлап киткән] йөз меңгә [кабат] җибәрдек, яки алар [күрер күзгә] күбрәкләр иде. [Газапның билгеләрен күргәннән соң] Алар иман китерделәр, Без исә аларны [әҗәлләре хакында әзәлдә билгеләнгән] бервакытка кадәр яшәттек».**

«Саффәт / Сафта торучылар», 37:147-148

Юныс галәйһиссәлам үз кавемен гөнаһлардан ярлыкау сораган, Аллаһыга иман китергән һәм аның кайтуын көткән хәлдә таба. Ул халык белән бергә-бер калып, аларны Раббыбызның әмерләрен һәм тыюларын үтәргә өйрәтә һәм аларны үз артыннан хакыйкый юлдан алып бара. Кавемдәшләре бернинди тайпылусыз аның артыннан иярәләр һәм иң яхшы рәвештә барлык дини кануннарны үтиләр.

Юныс галәйһиссәламнән соң да Аллаһы Тәгалә Ниневия халкына туры юлдан барган вакытта күпләгән бәрәкәтләр бирә. Озак еллар алар сәгадәттә һәм иминлектә яшиләр.

Әлеге нәсыйхәтнең хикмәте шунда ки, хакыйкатькә чакыручылар, төрле нахак бәлаләр тагуларына да карамастан, сабыр булырга тиешләр, чөнки кешеләр үзләренең адашуларында нык торырга һәм авырлыклар китерергә мөмкиннәр. Һәрбер кеше моның белән очрашкан. Бары сабыр итеп һәм ныклык күрсәтеп кенә башка кешеләрнең күңелләренә илтә торган юл ачыла, чөнки тырышлык бездән, ә уңыш – Аллаһыдан. Иманга чакыру һәм начарлыкны кире кагу гамәлен ташлап өметен югалтканнарны Аллаһы ничек җәзага тартасын кем дә булса беләме? Аллаһы мондый җәзалардан Үзе сакласын!

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин,**
**Татарстан Республикасы мөфтие**

# Аллаһыга тәвәккәл итеп яшик



Әгүүҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахиим. Җирләрнең, күкләрнең Раббысы булган, ошбу дөньяга саннары да билгесез булган пәйгамбәрләрен җибәреп, шушы пәйгамбәрләре аша безгә туры юлны – бәхет-сәгадәт юлын өйрәткән, аңлаткан, җиткергән Аллаһы Тәгаләгә күңел түрләребездән чыккан сәламнәребез ирешсә иде. Шушы дөньяга соңгы пәйгамбәр булып җибәрелмеш сөекле Пәйгамбәребез, хәбибебез, остазыбыз Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә дә салаватларыбыз, сәламнәребез һәм изге догаларыбыз ирешсен.

Шушы вәгазебездә Коръән аятьләре, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләре, тормышында булган вакыйгалар, хәлләр аркылы, Аллаһыга тәвәккәл итү, һәрнәрсәдә, һәр эштә Аңа таяну хакында сөйләрбез. Адәм баласы Аллаһы Тәгаләнең барлыгына, берлегенә ышанганнан соң, Аңа таяна белергә тиеш. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә изге Коръәни Кәримендә болай дип әйткән:

**«Иманучылар – Аллаһы искә алынган чакта [Аның бөеклеген олылап, мәңгелек бөеклегенә карата] йөрәкләре курку белән тулучылар, аларга Аның аятьләре укылган чакта, аларның иманнарын [куәт ягыннан] арттырыр, һәм алар [беркемгә дә өмет багламыйча, беркемнән дә курыкмыйча] Раббыларына гына тәвәккәл итәрләр [һәм бөтен эшләрен Аңа гына тапшырырлар]».**

«Әл-Әнфәл / Табышлар», 8:2

Безгә шушы Аллаһыга таяну – тәвәккәл итү, тапшыруны сүзгә генә кайтарып калмыйча, Аллаһыга таянуны гамәлләребез белән, эшләгән эшләребез белән дә исбатларга кирәк. Гыйбадәтнең бер өлеше – ул Аллаһыга таяну, тәвәккәл итү, тапшыру. Таяну дигән сүзне барыгыз да аңлыйсыз: аягы авырткан кеше таякка таяна, күзе күрмәгән кеше күзлек кия, җәяү барырга авыр, йә ерак булган вакытта адәм баласы машина, техника белән хәрәкәт итә. Ир кеше хатынына, хатын иренә таяна, балалар әти-әниләренә таяна. Ягъни таяну, тәвәккәл итү, тапшыру – кемнәндер йә нәрсәдәндер ярдәм өмет итү. Әмма бөтен тәвәккәлләүне, таянуларны эченә алган иман һәм Аллаһы Тәгалә бар. Аллаһы Тәгалә безгә – бәндәләренә, болай дип әйтә:

**«Син үлмәячәк булган Мәңге исәнгә тәвәккәл ит һәм Аны [өстен сыйфатлары белән] мактап [кимчелекле сыйфатлардан пакьләп] тәсбих ит. Ул колларының гөнаһларыннан хәбәрдар буларак җитә».**

«Әл-Фүркан / Аеручы», 25:58

Кулыңа алган таяк та чери, күзеңә кигән күзлек тә җимерелә, техника да ватыла. Беркайчан да үлмәгән, мәңге тере булган Зат бар – ул Аллаһы. Аллаһыга таян һәм тәвәккәл кылып яшә. Башка бер аятьтә Аллаһы Тәгалә болай дигән:

**«... [ныклы] карарга килсәң, шунда ук Аллаһыга тапшыр. Һичшиксез, Аллаһы [бөтен эшләрдә Аңа] тәвәккәл итүчеләрне сөя».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:159

Ягъни күңелеңдә бер эшне башкарырга ниятләдең икән, шушы эшең белән бергә Аллаһыга тәвәккәл ит. «Аллаһым, шушы эшемне хәерле ит», – дип күңелең белән уйлан, фикерлә.

Гайсә пәйгамбәр галәйһиссәлам олы пәйгамбәрләрнең берсе иде. Аңа Аллаһы Тәгалә могҗиза биргән иде: үл үлеләрне терелтә, авыруларны шифаландыра, сукырларның күзләрен ача, ишетмәүчеләрне, чукракларны да ишетә торган итә иде, хәтта урамнан барганда, өй эчендәге өстәлдә ни торуын да, нинди ризык булуын да әйтә иде. Балчыктан бер кош ясап, аңа өреп, аны очыра иде. Бу булган әйберләр, болар тарихи расланган.

Шундый бер вакыйга була. Озак еллар авырган бер хатын шифа табар өчен Гайсә галәйһиссәлам янына килә. Бу хатын Гайсә атлап барганда, аның чапанына кагыла һәм: «Әй, Гайсә, син мине шифаландырдың, син мине шифаландырдың», – дип кычкырып җибәрә. Гайсә борыла да: «Мин түгел. Сине үз иманың дәвалады», – дип әйтә.

Ягъни чын мәгънәсендә инануың, ышануыңның нәтиҗәсен күрә белүең сиңа шифа бирде. Әй, кардәшләр, кешенең эчендә чын күңелдән инанып, ышанып, шөбһәсез тәвәккәл итү генә нәтиҗәле була ала. Шуңа күрә, бигрәк тә мөселманнар, һәр эшләренең башларында да, азагында да, уртасында да Аллаһыга тәвәккәл итәргә тиешләр, чөнки бөтен нәрсә Аның кодрәте белән, Аның рөхсәте белән эшләнелә.

Коръәндә болай дип әйтелгән:

**«Кем дә кем Аллаһыга тәвәккәл кыла, аңа Ул җитә».**

«Әт-Талак», 65:3

«Мин Аллаһыга тапшырган идем», – дип әйтергә, сүздә генә тәвәккәлләргә мөмкин. Шулай ук күңелең белән ышанып тапшырырга була. Болар һәрберсе дә аерым нәрсәләр. Никадәр чын мәгънәсендә ышанып тапшырасың икән, шулкадәр нәтиҗәле була, эшеңне никадәр шөбһәле башлыйсың икән, нәтиҗәсе дә шулкадәр үк шөбһәле була.

Шуның өчен, мөхтәрәм газиз кардәшләрем, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер мөбарәк хәдисендә болай дип әйтелә: «Иң беренче зур гыйлем – Аллаһы Тәгаләне тану. Гыйлемнең иң ахыры – һәрбер эшебезне Аллаһыга тапшыру».

Ибраһим пәйгамбәр галәйһиссәлам белән булган вакыйганы һәрберегез дә беләдер. Шул заманда яшәгән имансыз, иман китерергә дә теләмәгән бер патша Ибраһим галәйһиссәламне үтерергә боера һәм бик зур учак ягарга куша. Вә шушы учакка ыргытып, Ибраһим пәйгамбәрне яндырырга тели. Китапларда: «Бик кечкенә кешене яндырыр өчен, бик зур учак ягыла», – дип әйтелә. Ул учакның янына да килә алмаслык була, шуңа күрә Ибраһим галәйһиссәламне катапультага, ягъни ядрәләр ата торган җайланмага куеп, шушы утка ыргыталар. Ул очып барганда, янына Җәбраил фәрештә килеп җитә һәм: «Әй, Ибраһим, телисеңме, мин сине коткарам?» – дип әйтә. Уйлап карагыз әле: Ибраһим галәйһиссәламне утка ыргыттылар. Ул утка атылды, утта яначак. Шулвакыт фәрештә килеп: «Ярдәм итимме? Таян миңа!» – дип әйтә. Ибраһим галәйһиссәлам: «Син үзең килдеңме, әллә сине Аллаһы җибәрдеме?» – дип сорый. Фәрештә: «Үзем килдем», – дип әйтә. «Үзең килгән булсаң, кит! Мин Аллаһы Тәгаләгә тапшырдым инде. Бөтен ут та, ут хөкеме дә Аның кулында», – дип әйтә Ибраһим галәйһиссәлам. Һәм риваятьләрдә: «Утка ыргытылган кеше бер бакчага төшә», – дип әйтелә. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«[Алар аны зур бер ут эченә аткан вакытта] Без: «Ий ут! Ибраһим өчен салкынлык һәм тынычлык бул!» – дидек».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:69

Ягъни утка ыргытылган вакытта да: «Инде үләм, беттем, беркем ярдәм итә алмый», – дигәндә дә, чын күңелдән Аллаһыга тәвәккәл иткән кеше, иншәАллаһ, нәтиҗәсез калмый. Аллаһы Тәгалә Үз ярдәмен күрсәтә. Күрегез! Менә бу иман камил булуның нәтиҗәсе.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә бер дога өйрәтте: «Һәр эшнең башында «Бисмилләһ», дип әйтегез. «Бисмилләһ»сез башланган эш никадәр уңышлы башланып китсә дә, аның азагы хәерле булмас», – дип әйтә. Өйдән чыгып киткәндә дә, өеңә кайтып кергәндә дә «Бисмилләһ» дигән сүзне әйтергә кирәк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бисмилләһи тәвәккәлтү галәллаһи», ягъни «Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл иттем». «Вә ләә хәүлә вә ләә куввәтә иллә билләһ», ягъни «Бөтен көч-куәт Аның кулындадыр», дип әйткән кеше һәртөрле яманлыктан, бозыклыктан, шәйтанның кагылуыннан да имин булыр, ерак булыр», – дип әйткән иде.

Аллаһы Тәгалә барыбызга да хакыйкый, дөрес иман насыйп итсен. Һәр эшебезнең башында, уртасында, азагында да бөтен әйбер Аллаһының ихтыярында икәнлекне исебездән чыгармасак иде. Һәм мөмкин кадәр бөтен эшләрне хәләл юл белән башкарып, Аллаһы Тәгалә рөхсәт иткән эшләрдә хәрәкәт итәргә Үзе насыйп итсен. Аллаһыдан ерак булып йөргән бәндәләргә дә Аллаһы Тәгалә иман юлына басарга, тәүфыйклы булырга насыйп кылсын, иншәАллаһ. Әәмин!

■ **Мансур (Әнсар) хәзрәт Мифтяхов,**
**Мәрҗани мәчете имам-хатыйбы**

# СӘҮДӘ ИТҮ



**Сорау: Нәрсә ул сәүдә?**

Җавап: Сәүдә – ул ризалык белән солых төзеп, мал-мөлкәтне алмашу яки сату-алу.

С.: Сату-алу солыхы ничек төзелә?

Җ.: Сәүдә солыхы «бирдем – кабул иттем» кәлимәләре үткән заманда әйтелеп төзелә. Мәсәлән, берсе «саттым», икенчесе «алдым» дисә, солых төзелгән булып санала.

С.: Әгәр солых төзүчеләрнең берсе ризалашса, икенчесенә риза булу вәҗиб булырмы?

Җ.: Юк, сату-алу өчен ике якның да риза булуы кирәк. Әгәр берсе килешүгә ризалашса, икенчесе теләсә – ризалаша, теләмәсә – юк. Әгәр шул урында торганда ризалашса, беренчесе үз ризалыгын кире кага алмый.

С.: Ни өчен сез ризалыкны билгеле бер урында тору белән бәйләдегез?

Җ.: Чөнки солых төзүчеләрнең берсе ризалык биреп, ул урыннан китсә, һәм икенчесе икенче бер урында ризалык бирсә, бу килешү гамәлдән чыга.

С.: Сатып алучы сатучыга, килешү төзелгәннән соң, сатып алынган әйбер хакында дәгъва күрсәтә аламы?

Җ.: Әйе, әгәр сатып алучы товарда җитешсезлек тапса, аның сатучыга кире кайтарып бирергә хакы бар.

С.: Ваклап түләү шарты белән сату-алу рөхсәт ителәме?

Җ.: Әйе, әгәр түләү шарты алдан килешенгән булса, рөхсәт ителә.

С.: Әгәр кеше сатып алганда товар күләменең яки озынлыгының микъдарын күрсәтмәсә, бу килешү дөресме?

Җ.: Дөрес, чөнки сатып алганда товарның күләмен күрсәтү килешүнең шартыннан саналмый.

С.: Үлчәнелгән ризыкны һәм бөртекне сатарга ярыймы?

Җ.: Ярый. Ләкин риба килеп чыгу сәбәпле, башка төр ризыкка алмаштырырга ярамый.

С.: Товар өчен түләнелгән сумманың микъдарын күрсәтү вәҗибме?

Җ.: Әйе, вәҗиб.

С.: Сатып алучыга: «Бодайны сиңа кувшинга тутырылган хәлдә сатам», – дисә, сатып алучы кувшиндагы бодай микъдарын белмичә кабул итсә, сату-алу дөрес буламы?

Җ.: Әйе, кувшин тулы булып, бодай микъдарын белмәсә дә, сәүдә дөрес булып санала.

С.: Әгәр бер көтү сарыкның һәрбер сарыгын бер дирһәм бәясе шарты белән сатса, сәүдәсе дөрес булырмы?

Җ.: Әбү Хәнифә фикеренчә, бер бөтен көтүне тулысынча сатарга ярамый. Ләкин берәм-берәм сарык итеп сатарга ярый.

С.: Сатып алучы товар сатып алганнан соң, сатып алынган товарда җитешсезлек тапса, сатып алучыга нинди эшләр рөхсәт ителә?

Җ.: Аның җитешсезлекнең бәясен кайтарып бирүне таләп итәргә хакы бар, шулай ук сатып алынган барлык товарын кире кайтарып, түләгән акчасын кире алырга да хакы бар.

С.: Әгәр сатып алучы товарында артыклык тапса, аңа нишләргә?

Җ.: Бу артык товарны сатучыга кайтарып бирергә кирәк.

С.: Әгәр бер кеше 100 м тукыманы 1 метрын 10 дирһәм бәясенә сатып алса, тукыманың озынлыгы 100 метрдан ким булса, аның нинди хокуклары бар?

Җ.: Сатып алучының сатучыдан товар акчасын кире алырга яки барлык тукыманы да кире кайтарып бирергә хак бар.

С.: Әгәр сатып алучы тукыманың 100 метрдан күбрәк икәнен күрсә, аңа нишләргә?

Җ.: Барлык товар сатып алучының милкеннән санала. Җир участогы да шулай була.

С.: Сатучы бер бәйләм тукыма сатканда: «10 бәйләмнән торган тукыманы, һәрбер тукымага унар дирһәм итеп, 100 дирһәмгә сатам», – дисә, соңыннан алучы артык яисә ким итеп тукыма сатылганын ачыкласа, аның хөкеме нинди?

Җ.: Ким булганы өчен, сатып алучы теләсә, җитмәгән кадәр түләгән акчасын яисә тукыманы сорарга хакы бар, ә артык калган очракта сату-алу булып саналмый.

С.: Кеше өй саткан. Килешүдә өйдән башка нәрсә турында сөйләшенмәгән. Сатуга тагын өй белән нәрсә керергә мөмкин?

Җ.: Өй белән өйалды һәм йозаклардан ачкычлар да санала.

С.: Әгәр дә кеше җир сатса, бу җирдә үскән үсемлекләр дә сатыламы?

Җ.: Җир сатылганда утыртылган үсемлекләр килешүдә әйтелгән булса да, булмаса да сатыла. Ә чәчелгән үсемлекләр килешүдә каралган булса гына сатылырга мөмкин.

С.: Берәү җимеш китерә торган агачны җимешләре белән сатты. Аның җимешләре кемгә тиеш?

Җ.: Әгәр дә сатып алучы алдан бернинди дә шартлар куймаган булса, җимешләр сатучыга була.

С.: Берәү агачтагы җимешләрне сатты, тик аның сыйфаты билгесез. Мондый сату дөресме?

Җ.: Әйе, дөрес. Сатып алучы җимешләрне, сыйфаты нинди булуга карамастан, җыярга тиеш. Әгәр дә килешүдә җимешләрнең азрагын агачта калдырырга, дип килешенгән булса, мондый сату-алу дөрес түгел.

С.: Сатучы агачтагы җимешләрнең билгеле бер өлешен калдыру шарты белән сата. Мондый килешү дөрес буламы?

Җ.: Юк, килешү дөрес түгел.

С.: Бодайны башакта килеш һәм шулай ук башка игеннәрен чистартылмаган хәлдә сату ярыймы?

Җ.: Мөмкин, тик башка төр товарга алыштырганда гына, чөнки шул ук төргә алыштырганда риба булырга мөмкин.

С.: Товар күп булып, товарны үлчәргә кирәк булса, үлчәгән өчен үлчәүчегә кем акча түләргә тиеш?

Җ.: Сатучы.

С.: Сатып алучының күп санда динарлары булып, аларны үлчәргә кирәк булса, үлчәгән өчен үлчәүчегә акчаны кем түли?

Җ.: Сатып алучы.

С.: Сатып алганда башта нәрсә бирелергә тиеш, акчамы яки товармы?

Җ.: Әгәр дә товар акчага сатылса, башта сатучыга акча, аннан соң алучыга товар бирелә, әгәр бартер яисә акча алмашуы булса, икесе дә бер үк вакытта бирелә.

## Товарның сыйфатына дәгъва итү

Әбү Йосыф белән Мөхәммәд , товарның сыйфатына дәгъвалау 3 көн эчендә кылынырга, әгәр дә гарантиясе алдан сөйләшенгән булса, товарны кире кайтару вакыты озынайтылырга мөмкин, дип саныйлар.

С.: Сатучы товарын сатканнан соң, кире кайтарырга теләсә, әмма сатып алучыда ул товар булмаса, бу очракта сатучының нинди хокуклары бар?

Җ.: Бу көн үтмәгән булса, сатып алучы товарның кыйммәтен түләргә, әгәр товар аның милкендә булса, товарны кайтарып бирергә тиеш була.

С.: Әгәр сатып алучы товарда җитешсезлек тапса, бу җитешсезлек товарның сатучы милкеннән чыгуына комачаулыймы?

Җ.: Әбү Хәнифә фикеренчә, комачауламый. Шулай ук аның фикере буенча, товар сатып алучының милке булып та саналмый.

С.: Әгәр товарда бернинди җитешсезлек тапмаган очракта да аны кире кайтарырга ярыймы?

Җ.: Әгәр алдан килешенгән булса, ярый.

С.: Килешү төзүчеләрнең берсе сату-алу үтәлгәнче һәм гарантия срогы тәмамланганчы үлсә, гарантия туктала, бу килешүне варисларга калдырырга мөмкинме?

Җ.: Гарантия туктала, варислар өстендә дә калмый.

■ **Мөхәммәд Гашыйк Иләһи Әл-Бәрни “Әттәсһил әз-зарури ли мәсәил Әл-Кудури” китабыннан**

# 2021 ЕЛ
# Һиҗри исәп буенча 1442–1443 еллар

| | | |
|---|---|---|
| 14 гыйнвар | 1 җөмәдәл-ахыр | |
| 13 февраль | 1 раҗәб | |
| 18 февральдән 19ына каршы төн | 6 раҗәбтән 7 раҗәбкә | Рәгаиб кичәсе |
| 10 марттан 11енә каршы төн | 26 раҗәбтән 27 раҗәбкә | Мигъраҗ |
| 14 март | 1 шәгъбан | |
| 27 марттан 28енә каршы төн | 14 шәгъбаннан 15 шәгъбанга | Бәраәт кичәсе |
| 13 апрель | 1 Рамазан | Рамазан ае башлана |
| 8 майдан 9ына каршы төн | 26 Рамазаннан 27 Рамазанга | Кадер кичәсе |
| 13 май | 1 шәүвәл | Ураза гаете |
| 11 июнь | 1 зөлкагъдә | |
| 11 июль | 1 зөлхиҗҗә | |
| 19 июль | 9 зөлхиҗҗә | Гарәфә көне |
| 20 июль | 10 зөлхиҗҗә | Корбан бәйрәме |
| 19,20,21,22,23 июль | 9,10,11,12,13 зөлхиҗҗә | Тәкбир Әт-Тәшрик көннәре |
| 9 август | 1 мөхәррәм | Һиҗри буенча 1443 ел башлану |
| 18 август | 10 мөхәррәм | Гашурә көне |
| 8 сентябрь | 1 сафәр | |
| 7 октябрь | 1 рабигыль-әүвәл | |
| 17 октябрьдән 18енә каршы төн | 11 рабигыль-әүвәлдән 12 рабигыль-әүвәлгә | Мәүлид Ән-Нәби |
| 6 ноябрь | 1 рабигыль-ахыр | |
| 5 декабрь | 1 җөмәдәл-әүвәл | |

# Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын уздыру буенча киңәшмә узды

18 нче декабрьдә, 2021 елда Татарстан Республикасында «Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы»на әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты һәм ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов рәислегендә ТР Президенты каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча советның берләштерелгән утырышы узды. Аның эшендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да катнашты.

Киңәшмә эше кысаларында катнашучылар көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча докладлар һәм чыгышлар тыңлады. Аннары ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендәге делегатлар 2021 елда Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын уздыру буенча төп чараларның республика планы проектын хуп лады. Моннан тыш, катнашучыларга Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын уздыру буенча төп чараларның республика планы тәкъдим ителде. Аерым алганда, киләсе елда төрле милли бәйрәмнәр, фестивальләр, конкурслар, айлыклар, күргәзмәләр, конференцияләр, семинарлар һ.б. үткәрү ниятләнә.

■ **dumrt.ru сайтыннан**



# Коръән сүрәләре



## Сүрәләр исеме

Коръән сүрәләренең үз исемнәре бар. Аларның кайберләре:

пәйгамбәрләрнең исемнәре белән: «Ибраһим», «Йосыф», «Мөхәммәд»;

күк җисемнәре белән: «Ән-Нәҗм / Йолдыз», «Әл-Камәр / Ай», «Әш-Шәмс / Кояш»;

сүрәләрнең беренче сүзләре яки хәрефләре белән: «Йәсин», «Та һа», «Каф», «Сад», «Нун»;

расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышында булган вакыйгалар: «Әл-Исра / Төнге күчеш», «Әл-Муҗәдәлә / Бәхәсләшү», «Әл-Хуҗурат / Бүлмәләр»;

кеше белән бәйләнгән: «Әл-Инсан / Кеше», «Ән-Ниса / Хатыннар», «Ән-Нәс / Кешеләр», «Мәрьям»;

галәмнәр һәм җәмгыятьләр белән бәйле: «Әл-Җинн / Җеннәр», «Әл-Мунәфикун / Монафикълар»;

Ахирәт дөньясы белән: «Әл-Кыямә / Кыямәт», «Ән-Нәбә / Хәбәр», «Әт-Тәквир / Төрү»;

хайваннар дөньясы белән: «Әл-Ганкәбут / Үрмәкүч», «Ән-Нәхл / Бал кортлары», «Ән-Нәмл / Кырмыскалар». Ә бер сүрә «Әт-Тин / Инҗир» дип атала.

## Сүрәләрнең аңлатмасы

«Бисмилләһи» сүзе Коръәннең ачкычы, ә «Фатиха» аның ишеге булып тора. «Фатиха» «Ачучы» дигәнне белдерә. Ул Коръәннең үзәге. Бу сүрәдә хәмед-сәналәр, мактаулар, бөекләүләр бары тик Аллаһыга гына тиеш булуы, һәм бары тик Аңа гына гыйбадәт кылырга, ярдәмне Аннан гына сорарга кирәклеге турында әйтелә.

Көндәлек тормышта: намаз укыганда һәм дога кылганда иң еш укыла торган сүрә – ул «Фатиха» сүрәсе.

«Фатиха» сүрәсеннән соң иң еш укыла торган сүрә булып «Әл-Ихлас» сүрәсе тора. «Ихлас» «ихласлы булу», «үзеңне дин буенча тоту» дигәнне белдерә. Бу сүрәдә Аллаһы Тәгалә Үзе хакында ачык рәвештә кыска гына итеп әйтә. Шуңа күрә бу сүрә «Тәүхид»(Аллаһының берлеге) нең үзәге булып тора.

Коръәннең иң еш укыла торган тагын бер сүрәсе – ул «Йәсин». Бу сүрә Коръәннең йөрәге дип санала. Анда Исламның төп нигезләре турында әйтелә, Аллаһының Берлеге һәм Кодрәте турында дәлилләр китерелә, кешенең барлыкка килүе һәм үлгәннән соң терелүе хакында сөйләнә.

«Әр-Рахмән» сүрәсе дә иң еш укыла торган сүрәләр рәтендә, чөнки бу сүрә Аллаһының иң матур исемнәренең берсе белән аталган. «Рахмән» «мәхлукъларга Рәхимлелек күрсәтүче» мәгънәсен белдерә. Биредә исламның төп нигезләре, Аллаһының Берлеге һәм Кодрәте турындагы дәлилләр китерелү белән беррәттән, Аллаһының кешеләргә биргән чиксез нигъмәтләре искә алына.

■ **Сәхифәне Айсылу Юлдашева әзерләде**




## ТҖ МДНнең «Хозур» нәшрият йорты Зәйнулла ишан Рәсүлевнең «Рисалә Хыдыйрия» китабын бастырды

ТР МДНнең «Хозур» нәшрият йорты Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның фәнни аңлатмалары белән күренекле татар дин галиме, суфи шәех Зәйнулла ишан Рәсүлевнең «Рисалә Хыдыйрия» хезмәтен дөньяга чыгарды. Зәйнулла ишанның 1908 елгы бу кыйммәтле китабы, озак вакыт бастырылмыйча торганнан соң, Камил хәзрәт 2020 елда БИАда гарәп телендә үзенең магистрлык эшен яклагач, тәүге тапкыр нәшер ителде.

Китап гарәп телендә, аның татарча тулы исеме – «Хозыр галәйһиссәламнең тормыш юлы һәм Ибн Тәймия вә аның тарафдарларын кире кагу хакындагы рисалә» дип яңгырый. Моңарчы «Рисалә Хыдыйрия» хезмәте бары шәехнең тормышына һәм иҗади мирасына караган аерым җыентыкларда гына телгә алына, әмма алар барысы да СССР халыкларының телләрендә язылган. «Рисалә Хыдыйрия» хезмәте буенча гарәп телендә фәнни тикшерүләр юк иде. Хәзер, бу әсәр комплекслы өйрәнелгәч, Рәсүлевнең чордашлары арасында тоткан урынын билгеләргә һәм аның сөнни мөселманнар гакыйдәсенә нигезләнгән карашларга ия булуын аңларга мөмкин.

Әлеге басманы «Хозур» нәшрият йорты кибетләрендә сатып алырга һәм җир йөзенең теләсә кайсы почмагыннан заказ бирергә мөмкин.

**Кибет:** Казан шәһ., Тукай ур., 36нчы йорт.
Тел.: +7 960 072-74-63;
**Склад:** Казан шәһ., Газовая ур., 14нче йорт.
Тел.: +7 (966) 250-00-09;
**Интернет-кибет:** huzurshop.ru (http://huzurshop.ru/).

# Ятимнәр малын ашау



Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Ятимнәрнең малларын золым белән [хаксызга] ашаган кешеләр карыннарын ут белән тутырачаклар һәм тиздән [мисалы булмаган бик куркыныч] ялкынга керәчәкләр»;**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:10

**«Балигълык яшенә җиткәнче, иң яхшы куллану [булган саклау һәм файда китерү юллары] белән генә булмаса, ятим малына якын килмәгез; үлчәүне вә авырлыкны билгеләүне гаделлек белән [төп-төгәл] башкарыгыз. Без һичкемгә көченнән килмәгәнне йөкләмибез. Сез сүз әйткән чакта, якыныгыз булса да, гадел булыгыз, [гадел булырга, әмер һәм тыюларын үтәү мәсьәләсендә] Аллаһыга биргән вәгъдәгезне тотыгыз. Ул [Аллаһы Тәгалә] боларны [үтәүне] сезгә әмер итте, бәлки, [бу хөкемнәр турында яхшылап бер] уйларсыз [һәм кирәк булганча гамәл кылырсыз]».**

«Әнгәм / Терлек», 6:152

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм санап киткән җиде олы гөнаһ арасында ятимнәрнең малын ашау да бар.

Тәрбиягә алган кеше шул малдан аларга рөхсәт ителгән өлешне генә кулланырга ярый, аннан артыгын куллану – харам, бу кешегә хәләл ризык, хәләл мал булмаячак. Ул (хәләл) өлешне ислам дине кануннарына һәм горефләренә таянып хисаплап чыгарып була. Ул өлешне хисаплаганда начар ниятләр булырга тиеш түгел.

# Хәмер куллану

**«[Расүлем!] Синнән хәмер [һәм акылны томалый торган башка нәрсәләр] һәм отышлы уеннар [кебек малга зарар китерә торган нәрсәләр] турында [Аллаһы Тәгаләнең хөкемен] сорыйлар. Әйт: «Аларның икесендә дә [сүз көрәштерү, бозыклык һәм ялган кебек афәтләр, зиһенне чуалту кебек зарарлар булганлыктан, куллануда] зур гөнаһ, әмма [икесендә дә] кешеләр өчен [кәеф һәм рәхәтлек, кыюландыру һәм җиңел акча эшләү кебек аз гына] файда да бар. Әмма һәр икесендә дә гөнаһ, файдаларына караганда, [бермә-бер] күбрәк». Янә [байлар] синнән [моңа кадәр малдан кемгә сарыф итәргә кирәклеген сораганнар иде, бу юлы] нәрсәне сарыф итәргә кирәклеген сорыйлар. Әйт: «[Ихтыяҗдан] Артыкны [бирегез һәм үзегезне мохтаҗ хәлгә төшермәгез]!» Аллаһы [сораулагыгызга җавап булган] аятьләрен сезгә шулай бәян итә, бәлки, сез [дәлилләрне һәм хөкемнәрне] фикерләп карарсыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:219

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе болай дип сөйләгән: «Исерткеч эчемлекләрне тыя торган аять иңгәннән соң кайбер сәхабәләр башкаларга: «Моннан соң хәмер куллану ширеккә тиң булачак», – дип әйттеләр.

Габдулла бине Гомәр хәмер куллануны иң олы гөнаһ дип санаган. Чыннан да, исерткеч эчемлек – бөтен яманлыкларның да башлангычы. Моннан тыш, Аллаһы Тәгалә эчкечене ләгънәт кылган.

Габдулла бине Гамр Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый хәдисен тапшырган. Ул: «Әгәр кем дә булса исерек хәлендә булып, намазын калдырса, бу – аннан, бөтен булган нигъмәтләре белән бергә, җир йөзен тартып алган кебек булыр. Ә исереклеге аркасында дүрт намазны калдырган кешегә Аллаһының «Тинетүль-Хәбәл» эчемлеген эчерергә хакы бар», – дип әйткән. Сәхабәләр: «Йә Аллаһының Илчесе! «Тинетүль-Хәбәл» нәрсә ул?» – дип сораганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ул – җәһәннәм әһелләренең үлекләре һәм каннары», – дип җавап биргән (Имам Әхмәд бине Хәнбәл, Мөснәд, 2/178, 189).

Җәбир радыяллаһу ганһе Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әлеге сүзләрен тапшырган:

«Аллаһының эчкече кешегә «Тинетүль-Хәбәл» эчемлеген эчерергә хакы бар». Сәхабәләр: «Тинетүль-Хәбәл» нәрсә ул?» – дип сораганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ул – җәһәннәм әһелләренең тирләре», – дип җавап биргән (Китаб Әл-Әшрибә, 2002).

«Кем бу дөньяда шәраб эчсә, ул кеше Ахирәттә аннан мәхрүм калыр» (Әл-Бохари, Китаб Әл-Әшрибә, 5775; Әл-Мөслим, Китаб Әл-Әшрибә, 2003).

«Кем бертуктаусыз хәмер эчеп, шул халәтендә үлсә, Аллаһы Тәгалә каршына күп илаһларга табынучы буларак килеп басар» (Әхмәд бине Хәнбәл, Мөснәд, 1/272), (Тәрҗемәченең искәрмәсе: һәрбер исертә торган һәм наркотик (әфьюн) матдәләр – харам. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Һәрбер исерткеч – шәраб һәм һәрбер исерткеч – харам», – дип әйткән (Әл-Мөслим, Китаб Әл-Әшрибә, 2003). «Әлеге хәдис кайсы гына төргә карасa да, ул исерткеч эчемлекләрнең, күпме күләмдә булуына карамастан, харам булганлыгына дәлил булып тора» (А. Даудголу, Сахих Әл-Мөслим Тәрҗемәви Шәрхе, 9/924).

■ **Имам Әз-Зәһәбинең «Әл-Кәбаир» китабыннан**

# Пәйгамбәребезгә яла ягу

## Ялган хәдисләр уйлап табу

Кайбер ислам галимнәре Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата ялган сүзләр әйтү (Пәйгамбәребез әйтмәгән сүзләрне, анык дип белдерү) – көферлек һәм исламнан чыгу була дип саный.

Дөреслектә, Аллаһы Тәгаләгә һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә яла ягучы кеше; хәләлне харам, харамны хәләл дип әйтүче кешеләр имансыз булалар. Галимнәрнең бүтән очракларга карата булган хөкемнәре бу хөкемнәрдән аерыла.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Миңа яла ягу (ялган хәдисләр уйлап чыгару, Пәйгамбәребез турында уйдырмалар чыгару) калган кешеләргә яла ягу белән тәңгәл түгел. Бу эшләрне аңлы рәвештә эшләүче кеше үзенә утта (җәһәннәмдә (ред.) урын әзерләсен», – дип әйткән (Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан).

Шулай ук: «Мөселманда алдалау һәм хыянәттән кала, төрле сыйфатлар (мөселман төрле холыклы) була ала (Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан).

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Минем исемнән ачык ялган сөйләүче кеше ике ялганчының берсе булып тора», – дип әйткән (Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

Бу хәдисләр ялган хәдисләрне уйлап чыгаруның тыелган эш икәнен күрсәтеп торалар.

# Төркиядәге «Әфәнде Күпере» татар авылының барлыкка килүе

Татарларның Төркиягә күченеп китүе язучы Мәхмүд Галәүнең (1886-1937) (чын исеме Мәхмүд Галәветдин улы Мәрҗани) «Мөһаҗирләр» ("Переселенцы") романында җентекләп тасвирланган. Роман 1933 елда язылган булган. Аның нигезен күченеп китеп, Төркия авылында нигезләнгән Сафа Миңлебайның сөйләгәннәре тәшкил итә. Күченеп киткәннән соң аның яңа урында хатыны Саҗидә вафат була. Моннан соң ул икенче хатыны артыннан кабат туган авылына кайта. Тормыш иптәше йөкле булганга күрә аны үзе белән алып китә алмый.

«Әфәнде Күпере» («Эфенди Кёп рюсю») авылы кешеләре әбибабалары күченеп киткән авылларның исемнәрен саклап калганнар. Бу Сарабиккулово (Сарабиккул) авылының икенче исеме Эби (Әби), Шугурово (Шөгер), Каркали (Керкәле), Старый Иштеряк (Иске Иштирәк), Новый Иштеряк (Яңа Иштирәк), Куакбаш, Каратай, Карабаш, Яхшы Каран һ.б. Аларның барысы да диярлек 1920 елларга кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязенә һәм Уфа губернасының Минзәлә өязенә кергән була. Хәзер алар Татарстан республикасының Лениногорск, Бөгелмә, Сарман районнарына керә.

Татарларның Төркиягә күчеп китүләре император Александр III нең (идарә итү еллары 1881-1894) Идел буе һәм Урал мөселманнарына карата кырыс сәясәт алып баруы белән бәйле. Ул идарә иткән чорларда мөселманнарга каршы барган эшчәнлек һәм миссионерлар ярдәме белән татарларны христианлаштыру омтылышы көчәйгән. Татарлар арасында актив эшчәнлекне Николай Ильминский (1822-1891) һәм Евфимий Малов (1835-1918) алып барган.


Иң беренче император Николай II (идарә итү еллары 1894 -1917) шушы ук сәясәт буенча эш итә. 1897 елда Рәсәй хакимияте тарафыннан Рәсәй тарихында беренче тапкыр халык санын алу оештырыла. Татарлар арасында бу хәбәр борчылуларга китерә. Халык арасында, бу эшләрнең максаты: мөселманнарның исәбен белү, әаннары аларны чукындырырга теләүләре аркасында оештырыла, дигән сүзләр тарала. Идел буе авылларының күпчелегендә бунтлар һәм буйсынмау очраклары кабынып китә.

Кайбер авылларда халык санын язарга дип килүчеләрне кыйнап, куып җибәрү очраклары да булган. Төп проблема шунда була: хакимияттәгеләр тарафыннан мөселманнарга халык санын алу максатлары хакында сөйләнми. Бу бик күп имеш-мимешләр барлыкка килеп, бунт кузгалуга китерә. Хәтта моннан соң да хакимияттәгеләр халыкны тынычландырырга ашыкмый, ә хәрби көчләрне күрсәтергә булалар. Халык санын алуда катнашырга теләмәгән авылларга казаклар һәм жандармнар җибәрелә һәм авылларда яшәүчеләр җәзага тартыла.

Иң кайнар киеренкелек учакларының берсе Бөгелмә өязенең татар авылларында була. Бирегә казаклар һәм жандармнар килә. Һәм кешеләрдән берәм-берәм сорау алулар оештырыла. Тәртипсезлекләрдә гаепле дип табылганнарны богаулар белән суд тикшерүе өчен Казанга җибәрәләр. Аларның кайберләре җәзага тартыла, ә калганнары Себергә каторга эшләренә сөрелә.

Авылларда яшәп калучылар да авырлыкларга дучар ителә: аларны баганаларга бәйләп куялар, кыйный торган булалар. Әмма жандармнар һәм казаклар халыкны бу рәвешле җәзалау белән генә канәгатьләнми. Алар йорт хайваннарын: сыерларны, сарыкларны, кәҗәләрне һәм кошкортны тартып ала башлый. Малның бер өлеше белән берничә ай шушы авылларда яшәгәндә туклансалар, калган өлешен үзләре белән алып китәләр. Бу хәлләр күпчелек татарларны Госманлы империясендә сыену урыны эзләргә мәҗбүр итә. Шул рәвешле, 1898 елда качып китүчеләр Госманлы империясенә килеп, анда «Әфәнде Күпере» исемле авылга нигез сала.

**■ Мөхсин Нурулла язмасы, islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә**



Төркиядә татар авылының барлыкка килүе (фотоның чыганагы: facebook.com)



# Озын гомернең сәбәбе

Әсмәи рахимәһуллаһи болай дип сөйли: «Мин йөз егерме яшьлек бер кешене күреп, бу яшькә җитүенең сәбәбен сорадым. Ул:

– Мин көнчелектән котылдым һәм шуңа күрә олы яшькә җиттем, – дип җавап кайтарды».

### Нәсыйхәт:

Көнчелек – башка кешеләрдә булган нигъмәтләргә күңел төшү һәм аларның бетүен теләү ул. Бу шайтанның сыйфаты. Көнче кеше әйтерсең лә: «Йә Аллаһы! Син нигъмәтләргә лаек булмаган колыңны нигъмәтләдең», – дип әйтә кебек.

**«Әллә соң алар Аллаһы Үзенең фазылыннан [Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм сәхабәләре кебек] кешеләргә биргән [пәйгамбәрлек, Китап һәм өстенлек кебек] нәрсәләрдән көнләшәләрме?»**

«Нисә / Хатыннар», 4:54

Көнчелек изге гамәлләрне юкка чыгара. Пәйгамбәребез көнчелектән сак булырга кушкан, чөнки ул, ут агачларны яндырган кебек, кешенең изгелекләрен юкка чыгара, дип әйткән (Әбү Давыд хәдисләр җыентыгыннан).

Димәк, кеше гомерен озынайта яки кыскарта торган әйберләр бар. Мәсәлән, туганлык җепләрен саклау гомерне озынайта торган гамәл булып тора. Пәйгамбәребез: «Ризыгы һәм гомер озынлыгы артуын теләгән кеше үзенең туганнарының һәм якыннарының хәлен белеп торсын һәм алар белән арасын өзмәсен», – дип әйткән.

# Өч җинаять

Бер хикмәт иясенә аның дусты килеп, болай дип әйткән:

– Бер кеше синең хакта фәлән-фәлән сүзләрне әйтте.

Бу кеше җавап итеп:

– Син минем хәлемне белергә килгәч, өч җинаять кылдың:

1) мөселман кардәшемә карата күралмау хисе туюга сәбәпче булдың;

2) минем йөрәгемә шөгыль таптың (элек мин кардәшем турында бернәрсә дә уйламый идем, ә хәзер мин мизгелгә булса да уйга калдым);

3) сиңа карата ышанычым бетте, чөнки башкаларның сүзләрен миңа ирештерүче, минем сүзләремне дә башкаларга ирештерер, – дигән.

### Нәсыйхәт:

**«[Расүлем!] Һичбер күпләп ант итүчегә, түбән булганга буйсынма. [Һәркемне] Хурлаучыга, [бозык уйлар белән] сүз йөртүчегә [дә буйсынма]. [Һәм, шулай ук] Игелеккә киртә салучыга, дошманга, гөнаһлыга. Дорфага, җитмәсә, зинадан туганга. Ул кеше мал һәм ир балаларга ия булса да [аңа иярмә]».**

«Нун», 68:10-14

Гайбәт таратучылар мәсьәләсендә катгый кисәтү бар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гайбәт таратучы җәннәткә кермәс», – дип әйткән.

Гайбәт таратучыларга ышанырга, аларны сөйләштерергә тырышырга ярамый, чөнки башкаларның сүзләрен сиңа ирештерүче, синең сүзләреңне дә бүтән кешеләргә илтеп җиткерәчәк.

# Рабига Әл-Гәдәвиянең гыйбадәте

Рабига Әл-Гәдәвия бик тә тәкъвалы хатын-кыз иде. Иртә җиткәч, минем үлем көнем җитте дип, кичкә хәтле гыйбадәттә булган. Төн җиткәч, бу төн үлем төнем дип, иртә җиткәнче гыйбадәттә үткәргән. Ул, үлем килгәнче, шул халәттә яшәгән.

### Нәсыйхәт:

Кеше һәр гыйбадәтен гомерендәге соңгы гыйбадәте дип башкарырга тиеш. Иртән уянгач та, бу көнне үләргә мөмкинлеген уйлап, көнен тиешле дәрәҗәдә үткәрергә тиеш. Нәкъ шул рәвешле төнен дә үткәрергә тиешле. Кич җиткәч, бәлки иртән йокыдан уяныр булмаячакны аңлау кирәк. Әгәр кеше һәрвакытта да боларны истә тотып, тормышын шул рәвешле кора алса, эш-гамәлләре тәртипкә киләчәк.

Әйе, кеше көнен-төнен гыйбадәттә үткәрә алмый. Әмма без һәрбер көн яки төн соңгысы булырга мөмкин икәнлеген истә тота алабыз, чөнки үлем көтмәгәндә килергә мөмкин. Локман галәйһиссәлам үзенең улына шундый нәсыйхәт биргән: «Ий минем улым! Тәүбә кылуны иртәгегә калдырма, чөнки үлем көтмәгәндә килергә мөмкин».

«Рухуль Бәйан» китабыннан

# Әбү Гобәйдә бине Җәррах радыяллаһу ганһе




## Тууы

Әбү Гобәйдә бине Җәррах радыяллаһу ганһе 582/583 елда Мәккә шәһәрендә Габдулла бине Әл-Җәррах гаиләсендә дөньяга килгән. Җәннәт белән шатландырылган ун сәхәбәнең берсе.

## Сыйфатлары

Әбү Гобәйдә бине Җәррах радыяллаһу ганһе күркәм йөзле, зифа буйлы, шат күңелле кеше булган. Матурлыгы, күркәмлеге, яктылыгы белән һәрвакыт кешеләрне үзенә җәлеп итә торган булган. Шул ук вакытта ул тыйнак, итагатьле, оялчан, ләкин берәр куркыныч янаган авыр вакытларда ул батыр арыслан һәм үткен кылыч кебек була алган.

## Һиҗрәт кылуы

Ислам динен кабул итү белән, гаиләсендә әтисе Исламга каршы булып, улының бу гамәлен кабул итмәгән һәм Әбү Гобәйдәне өеннән чыгарып җибәргән.

Әбү Гобәйдә бине Җәррах иң беренче һиҗрәт кылучылар арасында булган. Башка мөселманнар кебек ул да үз динен саклап калу максатыннан иң элек Хәбәшигә (Эфиопия), соңыннан Мәдинәгә һиҗрәт кылган. Мәдинәдә мөселман дәүләте төзүдә һәм аны ныгытуда үзеннән зур өлеш керткән.

## Аллаһы юлында үтелгән гомер

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән үзара килешү йөзеннән кул бирешкәннән соң, Әбү Гобәйдә бине Җәррах радыяллаһу ганһе үзенә бирелгән гомерне башкачарак кабул иткән. Ул тормышының барлык мәгънәсен Аллаһы юлында хезмәт итү, тормыш ләззәтләреннән баш тарту һәм төрле каршылыкларга каршы торуда күргән. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә аның шушы юлда тырышлыкларына, намуслыгына, төгәллегенә игътибар иткән.

Шулай бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына Нәҗраннан илчеләр килгәннәр һәм Аллаһы Расүленнән ышанычлы булган кешесен үзләре белән җибәрүен үтенгәннәр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларның үтенечләрен кабул итеп, үзенең иң ышанычлы булган кешесен җибәрергә әзер булуын белдергән. Шуны да искәртеп үтәргә кирәк, әлбәттә, һәр сәхәбә Аллаһының Расүле нәкъ менә аны сайлап алыр дип өметләнгән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм җыелган сәхабәләр арасыннан Әбү Гобәйдә бине Җәррахның торып басуын үтенгән һәм аның турында түбәндәге сүзләрне әйткән: «Һәр өммәтнең саклаучысы бар. Безнең өммәтнең саклаучысы – Әбү Гобәйдә бине Җәррах!»

Әбү Гобәйдә бине Җәррах ислам дине өчен бик күп хезмәт куйган һәм мөселманнар белән Мәккә мөшрикләре арасында барган барлык сугышларда да катнашкан. Бәдер сугышында ул үз әтисенә каршы көрәшкән, чөнки әтисе мөселманнарга каршы булып, мөшрикләр ягында булган. Риваятьләрдән күренгәнчә, Коръәни Кәримдәге «Әл-Мүҗәдәлә» сүрәсенең 22 нче аяте нәкъ менә Әбү Гобәйдә бине Җәррах һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең башка сәхабәләренә бәйле рәвештә иңгән дип санала.

**«Аллаһыга һәм Соңгы көнгә иман китергән кешеләрне – Аллаһыга һәм Аның пәйгамбәренә дошман булган кешеләрне дус иткән хәлдә тапмассың, хәтта ки алар, аларның аталары яки уллары, яки кардәшләре, яки ырулары булса да. Аларның йөрәкләренә Ул иманны язды [аны нык итте] һәм аларны Үзеннән бер рух [булган һәм җаннарының җаны урынында торган иман һәм Коръән нуры] белән куәтләндерде. Ул аларны [сарайлары һәм агачлары] асларыннан елгалар агып торган җәннәтләргә кертәчәк, һәм алар анда мәңге калачак. Аллаһы алардан разый, алар исә Аннан [Ул вәгъдә иткән әҗер-саваплардан] разый. Алар – Аллаһының тарафдарлары. Әйе, Аллаһының тарафдарлары, һичшиксез, [ике җиһан бәхетен казаначак] уңышка ирешүчеләр».**

«Әл-Мүҗәдәлә / Бәхәсләшү», 58:22

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең вафатыннан соң, өммәтебез белән Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе, ә аннан соң Гомәр хәлифә идарә иткән дәверләрдә дә Әбү Гобәйдә бине Җәррах дине өчен төрле сынауларга да каршы торуын дәвам иткән, көчле һәм ышанычлы булып калган. Бу тормышның әчесентөчесен татыса да, тәкъвалыгы һәм ныклыгы куелган максатларына ирешүдә һәм сайланган туры юлдан баруына нык ярдәм иткән.

Әбү Гобәйдә бине Җәррахның оста җитәкчелегендә Димәшкъ, Хомес, Кодес (Иерусалим) һәм башка бик күп шәһәрләр яулап алынган.

## Искиткеч ихласлыгы һәм тугрылыгы

Үзенә куелган вазифаларны намус белән башкаруы һәм әдәплелеге белән Әбү Гобәйдә бине Җәррах башкалардан шактый аерылып торган. Мәсәлән, Өхед сугышында дошманның төп максаты җиңү түгел, ә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне үтерү икәнлеген аңлагач, ул шуңа гел Аллаһы Расүле янында булырга тырышкан. Аңа куркыныч янаган вакытларда үз-үзен аямый мөмкин булганча Пәйгамбәребезне саклаган. Сугышның иң көчәйгән вакытында Әбү Гобәйдә бине Җәррахны берничә мәҗүси камап алган. Шулвакытта ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ук кадалганын күргән һәм дошман кулыннан ычкынып, тиз арада Аллаһының Расүленә ярдәмгә ашыккан. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең битенә кадалган тимерләрен теше белән суырып алган һәм үзенең ике тешен сындырган.

Икенче бер хәрби поход вакытында аңа үз гаскәриләре белән ач хәлендә күп чакрымнар үтәргә туры килгән. Монда да ул сынатмаган, үзен оста, көчле һәм ышанычлы җитәкче буларак таныткан.

## Тыйнаклыгы

Сүрияне яулап алу вакытында Әбү Гобәйдә бине Җәррах гаскәр җитәкчесе булып билгеләнгән. Аның гаскәре көчле һәм башка мөселман гаскәрләренә караганда шактый нык коралланган булган. Гаскәр җитәкчесе булса да, Әбү Гобәйдә бине Җәррахны гади гаскәридән аеруы бик авыр булган, чөнки ул бервакытта да таләпчән булмаган.

Сүриядәге халыкның аның җитәкче булып билгеләнүенә шатланганын белгәч, ул аларны бергә җыеп, түбәндәге сүзләр белән аларга мөрәҗәгать иткән: «Дусларым, мин Кораеш кабиләсеннән булган мөселманмын. Әгәр берәрегез миңа караганда тәкъвалырак һәм гаделрәк булса, мин аның тән төсенә дә карамыйча, шәүлә булып аңа иярәчәкмен».

Күргәнебезчә, Әбү Гобәйдә бине Җәррах тыйнак кына үзен Кораеш кабиләсеннән булган мөселман дип таныштырган. Үз-үзен сыйфатлау өчен шул сүзләр дә җиткән аңа.

Бервакыт Гомәр радыяллаһу ганһе Сүриягә килгән һәм үзен каршы алган күренекле кешеләрдән: «Минем Әбү Гобәйдә бине Җәррах кардәшем кайда?» – дип сораган. Озакламый Әбү Гобәйдә бине Җәррах килеп җиткән һәм Гомәр радыяллаһу ганһене кочаклап, үз өенә кунакка дәшкән. Гомәр радыяллаһу ганһе аның өенә кергәч гаҗәпкә калган, чөнки Әбү Гобәйдә бине Җәррах радыяллаһу ганһенең өендә кылыч, калкан һәм ияреннән башка бернәрсә дә булмаган. Гомәр радыяллаһу ганһе аннан: «Син үзеңә берәр нәрсә алыр идеңме?» – дип сораган. Әбү Гобәйдә бине Җәррах аңа болай дип җавап кайтарган: «Йоклар өчен өем бар һәм миңа шул җиткән».

Шамда ваба чире тарала башлагач, ул вакытта хәлифә булган Гомәр радыяллаһу ганһе борчылып Әбү Гобәйдә бине Җәррахка хат юллаган. Әбү Гобәйдә бине Җәррах җавап хатында үз гаскәре белән бергә калу теләге хакында әйткән. 638 елда Әбү Гобәйдә бине Җәррах шушы чирдән вафат булган.

Әбү Гобәйдә бине Җәррахның вафатыннан соң Гомәр радыяллаһу ганһе нык кайгырган, аның белән бәйле булган вакыйгаларны хәтерендә яңарткан. Күз яшьләренә тыя алмыйча Аллаһы Тәгаләдән дин кардәше өчен дога кылып сораган: «Әгәр дә мин теләк тели алсам, мин өйле булуны һәм ул өйнең Әбү Гобәйдә бине Җәррах кебек ирләр белән тулы булуын теләр идем», – дип әйткән.

■ *Сәхифәне Лилия*
**Хәләфетдинова әзерләде**

# Кайнар диңгез юлы

***Дәвамы. Башы алдагы санда***

...Себер җирендә таң иртә ата. Чөнки монда вакыт безгә караганда ике сәгатькә алда йөри. Таһир ялт кына урыныннан сикереп торды. Электр чәйнегендә су кайнатып, тәһарәт алды, намаз укыды. Кайнар чәй эчеп алды. Әнисе пешереп җибәргән ипине чәйнәгән саен йөрәгенә көч кергәнен тойды. Бүген аның тормышында ниндидер яңалык булыр кебек тоелды. Тулай торакның сиртмәле ишеген шыгырдатып ачып, урамга чыгуга, йөзенә салкын җил килеп бәрелде. Әйтерсең лә, йөзенә бозлы су аттылар. Йөзен учы белән каплый төшеп, салмак кына атлады. Урамнар буйлап бараклар тезелеп киткән. Анда-санда яңа биналар күтәрелеп килә. Каршысына олырак яшьтәге, башына түбәтәй кигән ир кеше килгәнен күреп, куанычыннан нишләргә белмичә, туктап калды. Ике кулын сузып исәнләште, Сургутка имам итеп җибәрелгәнен әйтеп, үзе белән таныштырды. «Наиф абыең булам, бик хуп, яшь күренәсең», – диде. Ул Таһирне үзләренә алып кайтты. Чәй өстәле янында бик озаклап сөйләшеп утырдылар.

– Энем, син бик вакытлы килдең, динсез гомер итеп булмый. Зур дини гыйлемем юк, шулай да бала тугач, исем кушарга мине чакырдылар. Үзлегемнән Коръән укырга өйрәндем. Заводта эшләүче Расих кордаш та намаз укый. Җомга намазын уку өчен 4 кеше булу шарт. Төпле урын булганчы, җомга намазын безнең өйдә укый торыйк.

Наиф абыйсының шушы сүзен ишеткәч, куанычыннан Таһирнең күзеннән яшенә кадәр бәреп чыкты.

– Намаз укый белүче кешеләрне беләсезме? Килсеннәр генә, белмәүчеләрне үзем өйрәтер идем, – дип өзгәләнде Таһир.

– Энем, күрәм, җаның-тәнең белән Аллаһка бирелгәнсең. Аллаһ боерса, синең кебек зур гыйлемле имам булганда, Себер җирендә дә дин күтәрелер...

...Җомга намазына Наиф йортына иң беренче Таһир килеп утырды. Ярты сәгать кала дүрт ир кеше килде. «Заводта бергә эшлибез», – дип таныштырды алар белән Наиф. Таһир башта вәгазь сөйләде. Аннары имамга оеп намаз укыдылар.

Таһир куанып кайтып керде. Ул хәттә баракның салкынлыгын да сизмәде, һәр җомга намазында сөйләргә төрле темага вәгазьләр әзерләү белән мәш килеп, төн үткәрде. Үз-үзенә, кат-кат сөйләп карады. «Үтемле вәгазь тыңлагач, кешенең иманы ныгып, күңеле сафланып калырга тиеш», – дия иде әтисе.

Икенче атнада җомга намазына килгәч, Рәис Латыйпов Таһирнең кулын кысты да:

– Яшь кенә булсаң да, гыйлемле имам син. Без синә, булышырбыз, бер команда булырбыз, – дип, күңелен тагын да күтәреп җибәрде.

– Команданы ишәйтер өчен, мәхәллә төзергә кирәк башта, Рәис абый, – диде Таһир.

– Заводта мәрхәмәтле кешеләр күп, барысын да тартырбыз, әкренләп, – диде дә: – Себердә мондый юка бишмәтләр белән генә салкыннан качып булмый, хәзрәт, мин сиңа җылы өс киеме алып килдем, – дип, зур сумкасыннан мех эчле кыш куртка чыгарды.

Таһир уңайсызланып булса да, куртканы киеп карады. Үзенә үлчәп тегелгән кебек таман икәнен күргәч, эченә җылы йөгерде. Ихлас күңеленнән олы рәхмәтләрен җиткерде.

– Салкыннар кайчанга кадәр дәвам итәчәк? – дип сорап куйды.

– Май аенда мондый салкын булганы юк иде. Сабантуй июньнең егермесенә билгеләнде, шуңа кадәр җир җылынып бетә.

Рәис Латыйповның ышанычлы итеп әйткән сүзен ишеткәч, Сабантуйга чакырып, Рәйсәгә шалтыратты.

***

Иреннән хәбәр алу белән, Рәйсә ике баласын юлга әзерли башлады.

– Бөтенләйгә бармыйсың ич әле, кызым, күп булса, бер атна торырсың, Камилне генә алып бар, Әлфинурны бездә калдырып тор, – диде әнисе.

Рәйсә әнисенең киңәшен тыңлады. Аларны аэропортка кадәр энесе Илфар озата килде. Салонга кергәч, Рәйсә башта Камилне урнаштырды.

– Йоклый алсаң – йокла, улым, яки китап укып утыр, – диде.

Камил сумкасыннан китап алды. Рәйсә үзе тәрәзә янына барып утырды. Мизгел эчендә уйлар чоңгылына кереп чумды. Беренче тапкыр Таһир яныннан кайтканнан бирле, Рәйсә үзенә урын таба алмады. Ирен сагынганын да, аның өчен борчылганын да туганнары алдында йөзенә чыгармады. Эчтән янды, эчтән көйде. Сирәк кенә телефоннан сөйләшкән вакытларда да сагынганын сиздереп, ирен борчымаска тырышты. «Синең янәшәңдә булсак, Себердә яшәргә дә риза, җаныем», – дигән сүзен генә әйтте.

...Рәйсә үзе җиде балалы ишле гаиләдә үсте. Ул үзенең сабыр холкын әнисенә охшата. Әти-әнисе аларны кече яшьтән намаз укытып үстерде. Коръәннән сүрәләр ятлатты, гарәп графикасына өйрәтте. Кем яхшы укый, әниләре шуңа илле тиен акча бирә иде. Әниләренең өч яшүсмер кызын елга бер тапкыр, кыш көне, Казанга Тынычлык бистәсендә яшәүче туганнары Муллаян абыйларга кунакка алып барганын исенә төшергәч, Рәйсә көлемсерәп куйды. Утырмага килгән балаларның барысын да чиратлап Коръән укыттыралар. Алар арасында әнисе Кәүсәрия абыстай белән Таһир дә килә иде. Киләчәк тормышы аның белән кушыласы булганга, биш-алты малай арасында күз алдында Таһир генә калды. Армиягә китәр алдыннан, әтисе белән Рәйсәләргә килгәч, ул аны шундук таныды, тик үзенә генә сиздермәде. Ә Таһир, аны таныганын шыпырт кына: «Мин сине күптәннән беләм, армиядән кайтуга, кулыңны сорарга киләм», – дип пышылдады. Рәйсә Лаеш авыл хуҗалыгы техникумында бухгалтер һөнәрен үзләштерде, Таһир белән дусларча хат алыштылар. Егет әйткән сүзендә торды: хәрби хезмәттән кайтуга, әти-әнисе белән Рәйсәне сорап килделәр. 1982 елның чатнама суык 15 гыйнварында туй ясадылар. Өйләнешкәч кенә, үзләренең яшүсмер чактагы оялчанлыкларын исләренә төшереп, көлешеп утырдылар. Рәйсә тирән итеп сулап куйды. Казанда төпләнеп яши генә башлагач, язмыш аларга яңа сынау җибәрде. Ул үз алдына: «Ашар ризыгыбыз Себердә булгач, бармый нихәл итәсең!» – дип кенә әйтеп куйды.

...1993 елның июнь ае. Таһир гаиләсен Сургут аэропортында каршы алды. Вакытлыча яшәп торырга Рәис Латыйповның әнисе йортына алып кайтып урнаштырды да, үзе ашыгыч эшем бар дип, китеп барды.

– Себергә дин нуры таратырга килгән кардәшләребезне баракта яшәтеп булмый, гаиләңне туп- туры үземә алып кайт, дидем хәзрәткә. Әйдәгез, узыгыз, – дип, Нәсыйха апа якты йөз белән каршы алды. Өч бүлмәле фатирының берсенә кунакларны урнаштырды.

– Аллаһы боерса, барысы да уң булыр, минем кебек, белгәне белән гамәл кылып яшәүчеләр байтак әле без монда. Иртәгә Сабантуйда барысы белән дә таныштырырмын, – дигәч, Рәйсә аңа күчтәнәч итеп алып килгән бер сумка Корбан ите бирде.

– Иии, кызым, шундый ерак җирләрдән зур күчтәнәчләр белән килгәнсең. Иртәгә мөселман кардәшләребезгә үз кулың белән бирерсең, – дип, итләрне суыткычка урнаштырды да: – Әйдәгез, табын янына узыгыз, үз йортыгыздагы кебек иркенләп утырыгыз, – диде.

Нәсыйха татар хатын-кызына хас булган кунакчыллык күрсәтте. Үзе пешергән түгәрәк ипине калын итеп кисеп, табынга куйды. Аннары камыр ризыклары чыгарды.

– Үзебезчә, тәмле итеп чәй эчик әле, – диде дә, Казандагы тормышлар белән кызыксынды.

–Ияләшкән идек инде Казанга да. Үзебез салган яңа йортыбызга күченеп яши башлаган идек тә... Монда да ияләшеп кенә китсәк ярар иде инде. Яңадан өр-яңадан тормыш башларга кирәк бит. Улыбыз татар гимназиясендә укыды, кызыбыз бакчада татар группасында йөрде. Икесе дә русча юньләп сөйләшә белмиләр. Аларга монда тел өйрәнергә кирәк булачак. Барысы да уйландыра инде, – диде Рәйсә.

Нәсыйханың бусагасыннан әле генә атлап кергән булса да, күптәнге дусты кебек якын итеп, күңелендәге уйлары белән бүлеште.

– Сургут җитәкчеләре үзләре чакырып китергәч, фатирын да бирерләр, мәчет салырга да ярдәм итәрләр. Авырлыкларны җиңеп чыкканчы сабыр итәргә туры килә инде, сеңлем. Монда төрле яктан җыелган халык арасында, диннең «д» хәрефен белмәүчеләре күбрәк. Аллаһ кулында барысы да, әгәр Себер җирендә ислам диненең җәелүен тели икән, барлык ишекләрне дә ачар.

– Без дә Аллаһ ярдәменә генә ышанып килдек, Нәсыйха апа. Менә үзегез дә безне якын туганнарыгыз кебек кабул иттегез.

– Казыксыз җирдә казык кагу өчен, бик диндар кеше булу кирәк. Таһир хәзрәт нәкъ шундый, гаярь ир солтаны. Аңа булышмый мөмкин түгел. Нәсыйха апа әйткән иде диярсең, Аллаһы боерса, Сургутыбызда биек манаралы мәчетләрдән азан тавышы яңгырар көннәрне дә күрербез, – дип, Нәсыйха Рәйсә белән Камилнең чәен яңартып бирде.

– Амин, – диде Рәйсә. – Шулай гына була күрсен...

***Дәвамы киләсе санда***

■ **Гөлсинә Галимуллина,**
**«Кайнар диңгез юлы»**
**повестеннән өзек**

**Хөрмәтле радиотыңлаучылар!**

"Азан" радиосы сайтының адресы үзгәрде. Хәзер безне azan.fm сылтамасы буенча таба аласыз. Иске мобиль кушымталар да үз эшен туктатты, аларны яңарту кирәк. Моның өчен, айфоннарда – App Store, андроидларда Play Market’ка кереп, "Азан радиосы" дип җыеп, "обновить" төймәсенә басарга кирәк. (Әгәр моңарчы телефоныгызда безнең кушымта булмаса, бер дә шикләнмичә куегыз). Әзер! Хәзер сез кая гына барсагыз да, бернинди түләүсез рәхәтләнеп татарча дини радио тыңлый аласыз.

**QR – кодлар:**

Android өчен:

iPhone өчен:

**Сайт:** azan.fm
**Инстаграм:** azan.fm
**Вконтакте:** azanfm
**Телеграм-канал:** azanfm
**Почта:** radio@azan.fm
**Тел.:** 8 (843) 598-09-43

**■ДҮШӘМБЕ, СИШӘМБЕ, ЧӘРШӘМБЕ, ПӘНҖЕШӘМБЕ, ШИМБӘ, ЯКШӘМБЕ**

0:00-5:59 Коръән
6:00-6:20 Коръән тәфсире
6:30-6:32 Көндәлек догалар
6:40-6:50 Таян Аллаһка
6:55-7:00 Хәзрәткә сорау
7:05-7:15 Иман тәме
7:20-7:23 Миллият сүзлеге
7:30-7:35 Гыйбрәтле кыйссалар
7:40-7:45 Әд-дин вә әдәп
8:10-8:17 Шәхесләргә шәрехләр
8:25-8:40 Сак булыгыз! Секталар!
8:50-8:55 Гыйбадәте Исламия
9:00-9:15 Күңелдән күңелгә
9:25-9:35 Тынычлык тәгълиматы
9:45-9:55 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)
10:00-10:15 Бәхет тулы йорт
10:20-10:25 Гыйбадәттә сәгадәт
10:30-10:45 101 вәгазь
10:55-10:57 Көндәлек догалар
11:00-11:15 40 хәдис
11:25-11:28 Миллият сүзлеге
11:40-11:50 Намаз дәресләре
12:00-12:04 Азан
12:30-14:00 Кәлам Шәриф – мәгънәви тәрҗемә
14:05-14:15 Пәйгамбәрләр тарихы
14:20-14:27 Мәчетләребез тарихы
14:30-14:40 Сөннәт юлы
14:45-14:50 Әд-дин вә әдәп
14:55-15:10 Әбү Хәнифә (р.г.)
15:15-15:20 Хәзрәткә сорау
15:25-15:30 Әхлак баскычлары
15:45-15:48 Миллият сүзлеге
16:00-16:20 Коръән тәфсире
16:25-16:27 Көндәлек догалар
16:30-16:40 Таян Аллаһка
16:50-17:00 Иман тәме
17:05-17:08 Миллият сүзлеге
17:10-17:15 Гыйбрәтле кыйссалар
17:20-17:25 Әд-дин вә әдәп
17:50-17:57 Шәхесләргә шәрехләр
18:00-18:15 Сак булыгыз! Секталар!
18:20-18:25 Гыйбадәте Исламия
18:30-18:45 Күңелдән күңелгә
18:50-19:00 Тынычлык тәгълиматы
19:05-19:15 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)
19:20-19:35 Бәхет тулы йорт
19:40-19:45 Гыйбадәттә сәгадәт
19:50-20:05 101 вәгазь
20:10-20:15 Көндәлек догалар
20:20-20:35 40 хәдис
20:40-20:43 Миллият сүзлеге
20:45-20:55 Намаз дәресләре
21:00-21:03 Нәниләргә нәсыйхәт
21:20-21:30 Пәйгамбәрләр тарихы
21:40-21:47 Мәчетләребез тарихы
21:50-21:55 Хәзрәткә сорау
22:00-22:10 Сөннәт юлы
22:15-22:20 Әд-дин вә әдәп
22:25-22:40 Әбү Хәнифә (р.г.)
22:45-22:50 Әхлак баскычлары
22:55-22:58 Миллият сүзлеге
23:00-5:59 Коръән

**■ҖОМГА**

0:00-5:59 Коръән
6:00-6:20 Коръән тәфсире
6:30-6:32 Көндәлек догалар
6:40-6:50 Таян Аллаһка
6:55-7:00 Җомга тәбриге
7:05-7:15 Иман тәме
7:20-7:23 Миллият сүзлеге
7:30-7:35 Гыйбрәтле кыйссалар
7:40-7:45 Әд-дин вә әдәп
8:10-8:17 Шәхесләргә шәрехләр
8:25-8:40 Сак булыгыз! Секталар!
8:50-8:55 Гыйбадәте Исламия
9:00-9:15 Күңелдән күңелгә
9:25-9:35 Тынычлык тәгълиматы
9:45-9:55 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)
10:00-10:15 Бәхет тулы йорт
10:20-10:25 Гыйбадәттә сәгадәт
10:30-10:45 101 вәгазь
10:55-10:57 Көндәлек догалар
11:00-11:15 40 хәдис
11:25-11:28 Миллият сүзлеге
11:30-11:35 Җомга тәбриге
11:40-11:50 Намаз дәресләре
12:00-12:04 Азан
12:30-14:00 Кәлам Шәриф – мәгънәви тәрҗемә
14:05-14:15 Пәйгамбәрләр тарихы
14:20-14:27 Мәчетләребез тарихы
14:30-14:40 Сөннәт юлы
14:45-14:50 Әд-дин вә әдәп
14:55-15:10 Әбү Хәнифә (р.г.)
15:15-15:20 Җомга тәбриге
15:25-15:30 Әхлак баскычлары
15:45-15:48 Миллият сүзлеге
16:00-16:20 Коръән тәфсире
16:25-16:27 Көндәлек догалар
16:30-16:40 Таян Аллаһка
16:50-17:00 Иман тәме
17:05-17:08 Миллият сүзлеге
17:10-17:15 Гыйбрәтле кыйссалар
17:20-17:25 Әд-дин вә әдәп
17:50-17:57 Шәхесләргә шәрехләр
18:00-18:15 Сак булыгыз! Секталар!
18:20-18:25 Гыйбадәте Исламия
18:30-18:45 Күңелдән күңелгә
18:50-19:00 Тынычлык тәгълиматы
19:05-19:15 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)
19:20-19:35 Бәхет тулы йорт
19:40-19:45 Гыйбадәттә сәгадәт
19:50-20:05 101 вәгазь
20:10-20:15 Көндәлек догалар
20:20-20:35 40 хәдис
20:40-20:43 Миллият сүзлеге
20:45-20:55 Намаз дәресләре
21:00-21:03 Нәниләргә нәсыйхәт
21:20-21:30 Пәйгамбәрләр тарихы
21:40-21:47 Мәчетләребез тарихы
21:50-21:55 Хәзрәткә сорау
22:00-22:10 Сөннәт юлы
22:15-22:20 Әд-дин вә әдәп
22:25-22:40 Әбү Хәнифә (р.г.)
22:45-22:50 Әхлак баскычлары
22:55-22:58 Миллият сүзлеге
23:00-5:59 Коръән

**Тапшырулар арасында эфирда кыска хәдисләр, нәшидләр һәм мөнәҗәтләр яңгырый*

# КАЗАН ӨЧЕН ГЫЙНВАР АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Көн Исеме | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы/ифтар | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.01.2021 | Җом | 05:53 | 06:42 | 08:12 | 12:00 | 13:34 | 15:21 | 17:18 |
| 02.01.2021 | Шим | 05:53 | 06:42 | 08:12 | 12:00 | 13:35 | 15:22 | 17:20 |
| 03.01.2021 | Якш | 05:53 | 06:42 | 08:12 | 12:00 | 13:36 | 15:23 | 17:21 |
| 04.01.2021 | Дүш | 05:52 | 06:41 | 08:11 | 12:00 | 13:37 | 15:25 | 17:22 |
| 05.01.2021 | Сиш | 05:52 | 06:41 | 08:11 | 12:00 | 13:39 | 15:26 | 17:23 |
| 06.01.2021 | Чәрш | 05:52 | 06:40 | 08:10 | 12:00 | 13:40 | 15:28 | 17:24 |
| 07.01.2021 | Пәнҗ | 05:52 | 06:40 | 08:10 | 12:00 | 13:41 | 15:29 | 17:25 |
| 08.01.2021 | Җом | 05:51 | 06:39 | 08:09 | 12:00 | 13:43 | 15:31 | 17:26 |
| 09.01.2021 | Шим | 05:51 | 06:38 | 08:08 | 12:00 | 13:44 | 15:32 | 17:28 |
| 10.01.2021 | Якш | 05:50 | 06:38 | 08:08 | 12:00 | 13:46 | 15:34 | 17:29 |
| 11.01.2021 | Дүш | 05:50 | 06:37 | 08:07 | 12:00 | 13:47 | 15:36 | 17:30 |
| 12.01.2021 | Сиш | 05:49 | 06:36 | 08:06 | 12:00 | 13:49 | 15:37 | 17:32 |
| 13.01.2021 | Чәрш | 05:49 | 06:35 | 08:05 | 12:00 | 13:50 | 15:39 | 17:33 |
| 14.01.2021 | Пәнҗ | 05:48 | 06:34 | 08:04 | 12:00 | 13:52 | 15:41 | 17:35 |
| 15.01.2021 | Җом | 05:47 | 06:33 | 08:03 | 12:00 | 13:54 | 15:43 | 17:36 |
| 16.01.2021 | Шим | 05:47 | 06:32 | 08:02 | 12:00 | 13:55 | 15:45 | 17:38 |
| 17.01.2021 | Якш | 05:46 | 06:30 | 08:00 | 12:00 | 13:57 | 15:46 | 17:39 |
| 18.01.2021 | Дүш | 05:45 | 06:29 | 07:59 | 12:00 | 13:59 | 15:48 | 17:41 |
| 19.01.2021 | Сиш | 05:44 | 06:28 | 07:58 | 12:00 | 14:01 | 15:50 | 17:42 |
| 20.01.2021 | Чәрш | 05:43 | 06:26 | 07:56 | 12:00 | 14:03 | 15:52 | 17:44 |
| 21.01.2021 | Пәнҗ | 05:42 | 06:25 | 07:55 | 12:00 | 14:04 | 15:54 | 17:45 |
| 22.01.2021 | Җом | 05:41 | 06:24 | 07:54 | 12:00 | 14:06 | 15:56 | 17:47 |
| 23.01.2021 | Шим | 05:40 | 06:22 | 07:52 | 12:00 | 14:08 | 15:58 | 17:49 |
| 24.01.2021 | Якш | 05:39 | 06:20 | 07:50 | 12:00 | 14:10 | 16:00 | 17:50 |
| 25.01.2021 | Дүш | 05:38 | 06:19 | 07:49 | 12:00 | 14:12 | 16:02 | 17:52 |
| 26.01.2021 | Сиш | 05:37 | 06:17 | 07:47 | 12:00 | 14:14 | 16:05 | 17:54 |
| 27.01.2021 | Чәрш | 05:35 | 06:16 | 07:46 | 12:00 | 14:16 | 16:07 | 17:55 |
| 28.01.2021 | Пәнҗ | 05:34 | 06:14 | 07:44 | 12:00 | 14:18 | 16:09 | 17:57 |
| 29.01.2021 | Җом | 05:33 | 06:12 | 07:42 | 12:00 | 14:20 | 16:11 | 17:59 |
| 30.01.2021 | Шим | 05:31 | 06:10 | 07:40 | 12:00 | 14:22 | 16:13 | 18:01 |
| 31.01.2021 | Якш | 05:30 | 06:08 | 07:38 | 12:00 | 14:24 | 16:15 | 18:03 |

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
*Декабрь саны, №12 (305)*

Баш мөхәррир: **Нәширбанов И.К.**
Мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБАРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2756
Газетага ярты елга язылу бәясе – 170,04 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 24 нче декабрьдә таратыла.
График буенча бу санга 23 нче декабрь көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.